**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.07.2016 № 377

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2016 елның 22 июлендә теркәлде, № 3438

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тикшерүләр үткәрү, үтәлүе мәҗбүри күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән, билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелек һәм контрольлек итү дәүләт функциясен үтәү буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 25.07.2012 № 592 боерыгы белән расланган административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актны Россия Федерациясе законы белән тәңгәлләштерү максатыннан *боерык бирәм:*

1. Кушымта итеп бирелүче яңа редакциядә бәян итеп, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тикшерүләр үткәрү, үтәлүе мәҗбүри күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән, билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелек һәм контрольлек итү дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентын раслау турында” 25.07.2012 № 592 боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 11.01.2013 ел, № 5, 25.09.2014 ел, № 518, 02.06.2015 ел № 366 боерыклары керткән үзгәрешләр белән) расланган

Тикшерүләр үткәрү, үтәлүе мәҗбүри күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән, билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелек һәм контрольлек итү дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына (алга таба – Административ регламент) үзгәрешләр кертергә.

2. Административ регламентның 1.8.3 пунктчасының унынчы һәм унберенче абзацлары бу боерык редакциясендә 2017 елның 1 гыйнварыннан көчләренә керә, дип билгеләргә.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының от 25.07.2012 ел, № 592 боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының от 02.07.2016 ел, № 377 боерыгы редакциясендә)

**Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тикшерүләр уздыруга, үтәлүе мәҗбүри күрсәтмәләр бирүгә һәм беркетмәләр төзүгә хокук белән, билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелек һәм контрольлек итү дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тикшерүләр уздыруга, үтәлүе мәҗбүри күрсәтмәләр бирүгә һәм беркетмәләр төзүгә хокук белән, билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелек һәм контрольлек итү дәүләт функциясен үтәү буенча бу административ регламенты (алга таба – Административ регламент) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык), тикшерүләр уздыруга, үтәлүе мәҗбүри күрсәтмәләр бирүгә һәм беркетмәләр төзүгә хокук белән, билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелек һәм контрольлек иткәндәге (алга таба – күзәтчелек һәм контроль) административ процедуралары (гамәлләре) срокларын һәм эзлеклелеген билгели.

Дәүләт функциясенең атамасы: тикшерүләр уздыруга, үтәлүе мәҗбүри күрсәтмәләр бирүгә һәм беркетмәләр төзүгә хокук белән, билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелек һәм контрольлек итү.

1.2. Дәүләт функциясен үтәүче булып Министрлык тора.

Тиешле мәгълүматны, 2008 елның 26 декабрендәге “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында” № 294-ФЗ Федераль законның 13.3 статьясына һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында” 28.04.2015 ел, № 415 карарына (алга таба – РФ Хөкүмәтенең № 415 карары) туры китереп, тикшерүләрнең бердәм реестрына кертү Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан башкарыла.

1.3. Күзәтчелек һәм контрольне башкарганда, Министрлык Татарстан Республикасы прокуратурасы органнары (алга таба – прокуратура органнары) һәм Татарстан Республикасы халык мәшгульлеге хезмәте органнары (алга таба –

халык мәшгульлеге үзәкләре) белән хезмәттәшлек итә.

1.4. Дәүләт функциясен үтәүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге:

Россия Федерациясенең 2001 елның 30 декабрендәге № 195-ФЗ Административ хокук бозулар турында кодексы (алга таба – РФ АХБК) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 1, 1 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 1, 3 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Россия Федерациясендә халыкның мәшгульлеге турында" 1991 елның 19 апрелендәге № 1032-1 Россия Федерациясе законы (алга таба – № 1032-1 Россия Федерациясе законы) (РСФСР Халык депутатлары съезды һәм РСФСР Югары Советы хәбәрләре, 1991, № 18, 565 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында" 1995 елның 24 ноябрендәге № 181-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 181-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү турында" 2006 елның 2 маендагы № 59-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 59-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 19, 2060 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2006 елның 27 июлендәге "Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны саклау турында" № 149-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 149-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31, 3448 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2008 елның 26 декабрендәге "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында" № 294-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 294-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, № 52, 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Электрон имза турында" 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., № 27, 3880 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан Юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны тикшерүләр уздыруның еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында" 30.06.2010 ел, № 489 карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең № 489 карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 12.07.2010, № 28, 3706 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының "Федераль дәүләт медицина-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан бирелүче: инвалидны тернәкләндерү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын, инвалид баланы тернәкләндерү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын һәм аларның формаларын төзү һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау

турында" 2015 елның 31 июлендәге № 528н боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 24.08.2015);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында" 30.04.2009 ел, № 141 боерыгы (алга таба – РФ Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы) (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан 2009 елның 13 маенда теркәлде, теркәү номеры – 13915, Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының "Тикшерүләр уздыруга, үтәлүе мәҗбүри күрсәтмәләр бирүгә һәм беркетмәләр төзүгә хокук белән, билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелек һәм контрольлек итү дәүләт функциясенең федераль дәүләт стандартын раслау турында" 2013 елның 30 апрелендәге № 181н боерыгы (Российская газета, 2013, 14 август, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы № 16-ТРЗ Татарстан Республикасы законы ("Республика Татарстан", 2003, 17 май кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Татарстан Республикасында халыкның мәшгульлегенә ярдәм итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында" 2006 елның 19 июнендәге № 39-ТРЗ Татарстан Республикасы законы ("Республика Татарстан", 2006, 27 июнь, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен квота булдыру һәм эш урыннарын резервта тоту турында" 2006 елның 24 июлендәге № 60-ТРЗ Татарстан Республикасы законы (алга таба – № 60-ТРЗ ТР законы) ("Республика Татарстан", 2006, 28 июль, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә башкаручы эш бирүчеләрдә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары квотасын булдыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында" 04.05.2007, № 170 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 170 ТР МК карары) ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы" журналы, 2007, № 19, 0673 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре" 15.08.2007 ел, № 388 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 388 ТР МК карары) ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы" журналы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.5. Күзәтчелек һәм контроль объектлары булып, оештыру-хокукый формаларына һәм милек формаларына бәйсез рәвештә – юридик затлардар, эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә башкаручы, хезмәткәрләренең исемлектәге уртача саны 35 кешедән ким булмаган һәм, Россия

Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китереп, инвалидларны эшкә алу өчен аларга квота билгеләнгән шәхси эшкуарлар (алга таба – тиңдәшле рәвештә – юридик затлар, шәхси эшкуарлар, шулай ук икесе бергә “эш бирүче” дип исемләнүчеләр) тора (дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан, инвалидларның иҗтимагый берләшмәләреннән һәм алар төзегән оешмалардан, шул исәптән устав (тупланма) капиталы инвалидларның иҗтимагый берләшмәсе кертеменнән торган хуҗалык итүче ширкәтләр һәм җәмгыятьләрдән, шулай ук закон белән билгеләнгән тәртиптә аларны бетерү турында карар кабул ителгән оешмалардан гайре).

1.6. Күзәтчелек һәм контроль предметы булып юридик затларның, шәхси эшкуарларның эш бирүчеләргә (юридик затларга, шәхси эшкуарларга) билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә алу йөкләмәләрен башкару буенча закон белән гамәлгә кертелгән таләпләрне үтәве, шулай ук Министрлыкның вазыйфаи заты күрсәтмәләрен үтәве, гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә зыян китерелүне булдырмау буенча, китерелгән андый зыянның нәтиҗәләрен бетерү буенча чаралар уздыруы тора.

1.7. Дәүләт функциясен үтәү тикшерүләрнең түбәндәге төрләрен (алга таба – тикшерүләр) үткәрү юлы белән башкарыла:

план буенча (урынга барып, документларны) тикшерү;

планнан тыш (урынга барып, документларны) тикшерү;

1.8. Күзәтчелек һәм контрольне башкарганда, Министрлыкның һәм аның вазыйфаи затларның хокуклары һәм бурычлары

1.8.1. Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар, тикшерү үткәргәндә, түбәндәгеләргә хокуклы:

күчмә тикшерү үткәргәндә, тикшерелүче юридик затлар, шәхси эшкуарлар янына барырга (хезмәт итү таныклыгын күрсәтеп һәм министрның (министр урынбасарының) тикшерү үткәрү турында боерыгы (әмере) күчермәсен юридик затның җитәкчесенә, шәхси эшкуарга биреп);

тикшерелә торган оешма белән граждан-хокук һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаучы экспертларны, эксперт оешмаларын план буенча шул оешмага барып тикшерү үткәрүгә җәлеп итәргә.

Министрлык карамагында булган документлардагы мәгълүматларның дөреслеге нигезле шикләр тудырган яисә бу мәгълүматлар юридик затның, шәхси эшкуарның мәҗбүри таләпләрне үтәвен бәяләргә мөмкинлек бирмәгән очракта, юридик зат адресына, шәхси эшкуар адресына, документларны тикшерү үткәрү барышында карап тикшерү өчен кирәкле бүтән документларны тапшыру таләбе белән, дәлилләнгән рәсми мөрәҗәгать җибәрәләр. Рәсми мөрәҗәгатькә кушымта итеп, министрның (министр урынбасарының) тикшерү үткәрү турында яисә документларын тикшерү турында әмере яки боерыгының мөһер белән расланган күчермәсе куела.

Министрлык дәүләтнең бүтән органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан бу документлар һәм (яки) мәгълүмат алар карамагында торган, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелгән

документлар һәм (яки) мәгълүматны, шул исәптән электрон рәвештә, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысасында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән срокларда һәм тәртиптә сорарга һәм түләүсез нигездә алырга хокуклы.

1.8.2. Тикшерү үткәрүгә вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлар, тикшерү үткәргәндә, түбәндәгеләргә бурычлы:

мәҗбүри таләпләр бозылуны кисәтү, ачыклау һәм аңа юл куймау буенча Россия Федерациясе законына туры китереп бирелгән вәкаләтләрен вакытында һәм тулы күләмдә үтәргә;

Россия Федерациясе законын, тикшерелә торган юридик затларның, шәхси эшкуарларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен сакларга;

тикшерү билгеләүгә тәңгәл рәвештә, тикшерүне министр, министр урынбасарының аны уздыру турында әмере яки боерыгы нигезендә үткәрергә;

тикшерүне бары тик хезмәт йөкләмәләрен үтәгән вакытта гына уздырырга; урынга барып тикшерүне бары тик эш буенча куллана торган таныклыкларын һәм министрның, министр урынбасарының тикшерү үткәрү турында әмере яки боерыгы күчермәсен күрсәтеп кенә үткәрергә, ә урынга барып, гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерелү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), дәүләт иминлегенә зыян китерелү (зыян китерелү куркынычы туу), шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү (барлыкка килү куркынычы туу) фактлары буенча планнан тыш тикшерү үткәргән очракта, шулай ук тикшерү үткәрүнең прокуратура органы белән килештерелгәнлеге турында документ күчермәсен дә күрсәтергә;

юридик затның җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү үткәргәндә шунда булырга һәм тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә комачауламаска;

юридик затның тикшерү үткәргәндә катнашучы җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына кагылышлы мәгълүмат һәм документларны бирергә;

юридик затның җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яки вәкаләтле вәкилен, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга;

юридик затның җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яки вәкаләтле вәкилен, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысасында алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән таныштырырга;

ачыкланган хокук бозу фактлары буенча күрелүче чараларны билгеләгәндә, әлеге чараларның хокук бозулар авырлыгына тәңгәл килүен, аларның кешеләрнең гомере, сәламәтлеге өчен, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохит, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей

предметлары һәм музей коллекцияләре, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документлары, Илкүләм китапханә фонды составына керүче аерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документлар өчен, дәүләт иминлеге өчен, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу өчен ихтимал куркынычын исәпкә алырга, шулай ук гражданнарның, шул исәптән шәхси эшкуарларның, юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен нигезсез чикләүгә юл куймаска;

аларның гамәлләренә карата юридик затлар, шәхси эшкуарлар Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә шикаять белдергәндә, үз гамәлләренең нигезлелеген исбатларга;

тикшерү үткәрүнең № 294-ФЗ Федераль закон белән билгеләнгән срокларын сакларга;

юридик затлардан, шәхси эшкуарлардан аларны күрсәтү Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылмаган документлар һәм бүтән мәгълүматлар таләп итмәскә;

урынга барып тикшерү үткәрү алдыннан, юридик затның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең үтенече буенча, аларны бу Административ регламент нигезләмәләре белән таныштырырга;

үткәрелгән тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналына Министрлыкның атамасы, тикшерү үткәрүнең башлану һәм тәмамлану көннәре, аны үткәрү вакыты, тикшерүнең хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм предметы, ачыкланган хокук бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турында мәгълүматларны эченә алган язу язып куярга, шулай ук тикшерү үткәрүче вазыйфаи затның яки вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм вазыйфалары, аның яки аларның имзалары күрсәтелә. Тикшерүләрне исәпкә алу журналы булмаганда, тикшерү актында бу хакта язып куела.

1.8.3. Тикшерү үткәрүгә вәкаләт бирелгән вазыйфаи затларның, тикшерү үткәргәндә, түбәндәгеләргә хакы юк:

әгәр андый таләпләр Министрлык вәкаләтләренә кермәсә, мәҗбүри таләпләрнең һәм муниципаль хокукый актлар белән гамәлгә кертелгән таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

СССР һәм РСФСРның башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары белән гамәлгә кертелгән һәм Россия Федерациясе законына туры килмәүче таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

Россия Федерациясе законы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылмаган хокукый актлар белән гамәлгә кертелгән мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

аны үткәргәндә, юридик затның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар булмаган очракта, урынга барып, план буенча яки планнан тыш тикшерү үткәрергә (андый тикшерүне гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә зыян китерелү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих

һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, Илкүләм китапханә фонды составына керүче аерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга, дәүләт иминлегенә зыян китерелү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу нигезе буенча үткәрү очрагыннан гайре);

тикшерү объектлары булып тормаучы яки тикшерү предметына кагылышы булмаган документлар, мәгълүматлар бирүне таләп итәргә, шулай ук андый документларның төп нөсхәләрен тартып алырга;

Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган очраклардан гайре, тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт итү сере, закон белән сакланылучы бүтән сер булып торучы мәгълүматны таратырга;

тикшерү үткәрүнең билгеләнгән срокларын арттырырга;

контроль чараларын алар хисабыннан уздыру турында юридик затка, шәхси эшкуарга күрсәтмәләр яки тәкъдимнәр бирергә.

дәүләтнең бүтән органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар карамагында булып, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелгән рөхсәт итүче документларны да кертеп, документлар һәм (яки) мәгълүмат бирүне юридик заттан, шәхси эшкуардан таләп итәргә;

Россия Федерациясе законы таләпләренә туры китереп, элегрәк бирелгән һәм (яки) дәүләтнең яки муниципалитетның мәгълүмат системаларында, реестрларында һәм регистрларында торган мәгълүматны бирүне юридик заттан, шәхси эшкуардан таләп итәргә.

1.9. Аларга карата дәүләт күзәтчелеге һәм контроле чаралары күрелә торган юридик затларның, шәхси эшкуарларның хокуклары һәм бурычлары

1.9.1. Юридик затның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле, тикшерү үткәрелгәндә, түбәндәгеләргә хокуклы:

тикшерү үткәрелгәндә турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

Министрлыктан, аның вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына кагылышы булган һәм аны бирү № 294-ФЗ Федераль закон белән күздә тотылган мәгълүматны алырга;

Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары дәүләтнең бүтән органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан алар карамагында торучы документлар һәм (яки) мәгълүматны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысасында алган әлеге документлар һәм (яки) мәгълүмат белән танышырга;

ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысасында сорап алынучы документлар һәм (яки) мәгълүматны дәүләт контроле (күзәтчелеге) органына үз инициативасы белән тапшырырга;

бу Административ регламентның 1.9.2 пунктының бишенче абзацында

күрсәтелгән очракта, өстәмә рәвештә, Министрлыкка элегрәк тапшырылган документларның дөреслеген раслаучы документлар тапшырырга;

тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм үзенең тикшерү нәтиҗәләре белән танышканлыгы, алар белән, шулай ук Министрлыкның вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән килешүе яки килешмәве хакында тикшерү актына язарга;

Министрлыкның вазыйфаи затларының, тикшерү үткәргәндә, юридик затның, шәхси эшкуарның, юридик затның, шәхси эшкуарның вазыйфаи затларының хокуклары бозылуга сәбәп булган гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата административ һәм (яки) суд тәртибендә, Россия Федерациясе законнарына туры китереп, шикаять белдерергә;

тикшерүдә катнашуга Эшкуарларның хокукларын яклау буенча Россия Федерациясе Президенты каршындагы вәкаләт иясен яисә Эшкуарларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы вәкаләт иясен чакырырга;

контроль (күзәтчелек) чараларын гамәлгә ашырганда, Министрлыкның вазыйфаи затларының Россия Федерациясе законы белән билгеләнгән тәртиптә законсыз дип танылган гамәлләре (гамәл кылмаулары) аркасында китерелгән зыянны каплауга.

1.9.2. Юридик затларның, шәхси эшкуарларның бурычлары

Юридик затның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле күчмә тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларның һәм күчмә тикшерүдә катнашучы экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең территориягә, үз эшчәнлекләрен башкарганда юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан файдаланыла торган биналарга, төзелмәләргә, корылмаларга, бүлмәләргә каршылыксыз керә алуын тәэмин итәргә бурычлы.

Тикшерүләр үткәрелгәндә, юридик затлар үз җитәкчеләренең, башка вазыйфаи затлары яки вәкаләтле вәкилләренең шунда булуын тәэмин итәргә бурычлы; шәхси эшкуарлар шунда булырга яки оешманың мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча чараларны оештыру һәм уздыруга җаваплы вәкаләтле вәкилләренең шунда булуын тәэмин итәргә бурычлы.

Министрлыкның тикшерү үткәрүгә вәкаләт бирелгән вазыйфаи затларына аларны тапшыру Россия Федерациясе законы белән күздә тотылган мәгълүматлар һәм документлар, шулай ук тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча телдән һәм язмача аңлатмалар бирергә бурычлы.

дәлилле рәсми мөрәҗәгатьне алган көннән башлап ун эш көне эчендә, юридик зат, шәхси эшкуар рәсми мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән документларны Министрлыкка җибәрергә бурычлы.

Юридик зат, шәхси эшкуар, документларын тикшерү барышында юридик зат, шәхси эшкуар тапшырган документларда хаталар һәм (яки) капма-каршылыклар ачыклану яисә бу документлардагы мәгълүматларның Министрлыкта булган документлардагы һәм (яки) дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру барышында алынган мәгълүматларга туры килмәве турында, кирәкле аңлатмаларны бирүне таләп итеп, мәгълүмат кергәч, әлеге таләп

кергән көннән алып ун көнлек срокта Министрлыкка тапшырылган документларда ачыкланган хаталар һәм (яки) капма-каршылыкларга кагылышлы яисә әлеге мәгълүматларның туры килмәвенә кагылышлы язмача аңлатмалар җибәрә.

1.10. Дәүләт функциясен үтәүнең нәтиҗәсе булып юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендә закон бозылуның булуын яки булмавын ачыклау тора.

1.11. Дәүләт функциясен үтәү түбәндәгеләрне төзү белән тәмамлана:

тикшерү акты (тикшерү актының РФ Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган типовой формасы нигезендә);

тикшерүләрне исәпкә алу журналына урынга барып уздырылган тикшерү турында язып кую (тикшерүләрне исәпкә алу журналының формасы РФ Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган);

№ 294-ФЗ Федераль законның 13.3 статьясына һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең № 415 карарына туры китереп, тикшерүләрнең бердәм реестрына шул хакта кертелгән мәгълүмат;

мәҗбүри таләпләр бозылу ачыкланган очракта:

халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендә закон бозуларны бетерү турында күрсәтмә (закон бозу факты ачыкланган очракта) (бу Административ регламентка 5 нче кушымтадагы үрнәк форма);

беркетмә:

РФ АХБКның 5.42 статьясындагы 1 өлеш белән күздә тотылган административ хокук бозу турында (закон бозу факты ачыкланган очракта);

РФ АХБКның 19.7 статьясы белән күздә тотылган административ хокук бозу турында (закон бозу факты ачыкланган очракта).

Дәүләт функциясен үтәү өчен нигез булып Министрлыкка гражданнарның, шул исәптән оешмаларның мөрәҗәгатьләре һәм гаризалары, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан (алга таба – гариза бирүче) мәгълүмат керү торган очракта, гариза бирүчегә дәүләт функциясен үтәүнең нәтиҗәләре буенча № 59-ФЗ Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә җавап җибәрелә.

## 2. Дәүләт функциясен үтәү тәртибенә карата таләпләр

2.1. Дәүләт функциясен үтәү турында мәгълүмат бирү тәртибе:

2.1.1. Министрлыкның урнашкан урыны: Казан ш., Волгоград ур., 47 й., тел. (843) 557-20-01, факс 520-92-87.

Министрлыкның эш графигы: шимбә, якшәмбе һәм эшләми торган бәйрәм көннәреннән тыш көн саен, 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькәчә төшке ашка бүленеп, 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькәчә (җомга көннәрендә – 16.45 сәгатькәчә).

Министрлыкның урнашкан урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәре (алга таба – “Интернет” челтәре) аша:

Министрлыкның рәсми сайтында;

Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефоннан);

Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

2.1.2. Дәүләт функциясен үтәү буенча белешмә мәгълүмат Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан (843) 557-20-93; 557-20-30 телефоннары аша бирелә.

2.1.3. Министрлыкның “Интернет” челтәрендәге рәсми сайты адресы: http://mtsz.tatarstan.ru.

Электрон почта адресы: mtsz@tatar.ru.

Министрлыкка дәүләт функциясен үтәү мәсьәләләре буенча документлар һәм мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен почта адресы: 420044, Казан ш., Волгоград ур., 47 й.

2.1.4. Татарстан Республикасы халык мәшгульлеге хезмәте дәүләт учреждениеләренең (алга таба – халык мәшгульлеге үзәкләре) урнашкан урыннары, аларның адреслары һәм телефоннары бу Административ регламентка 1 нче кушымтада китерелгән.

2.15. Министрлыкның һәм халык мәшгульлеге үзәкләренең урнашкан урыннары, телефоннары, эш графиклары турында мәгълүмат тиңдәшле рәвештә бирелә:

Министрлык телефоннары аша: 557-20-01, 557-21-13, халык мәшгульлеге үзәкләренең бу Административ регламентка 1 нче кушымтада күрсәтелгән телефоннары аша;

Министрлыкның “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтында – http://mtsz.tatarstan.ru;

Министрлык, халык мәшгульлеге үзәкләре биналарындагы мәгълүмат стендларында.

2.1.6. Бу Административ регламент турында мәгълүматлар Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының рәсми сайтына (http://www.mert.tatarstan.ru) урнаштырылган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләре үтәлүнең административ регламентлары бердәм реестрына кертелә.

2.17. Дәүләт функциясе һәм аны үтәү тәртибе турында мәгълүмат бирү Министрлык һәм халык мәшгульлеге үзәкләре биналарында массакүләм мәгълүмат чараларын, электрон элемтә яки, автоматик рәвештә мәгълүмат бирүне дә кертеп, телефон элемтәсен, “Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы” (http://www.gosuslugi.ru, алга таба – Бердәм портал) федераль дәүләт мәгълүмат системасын һәм (яки) төбәк порталын – “Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы”н (http://uslugi.tatar.ru, алга таба – Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы) да кертеп, “Интернет” челтәрен файдаланып башкарыла.

2.2. Күзәтчелек һәм контроль чараларын уздырган өчен юридик затлардан, шәхси эшкуарлардан түләү алуның рөхсәт ителмәве

Күзәтчелек һәм контроль чараларын уздырган өчен, шул исәптән экспертлар һәм эксперт оешмалары хезмәтләре өчен дә (аларны тикшерү үткәрүгә җәлеп иткән очракта) юридик затлардан, шәхси эшкуарлардан түләү алынмый.

2.3. Дәүләт функциясен үтәү срогы

2.3.1. Урынга барып, план буенча тикшерү үткәрү срогы 20 эш көненнән артырга тиеш түгел.

Документларны план буенча тикшерү үткәрү срогы 20 эш көненнән артырга тиеш түгел.

Урынга барып, планнан тыш тикшерү үткәрү срогы 20 эш көненнән артырга тиеш түгел.

Документларны планнан тыш тикшерү үткәрү срогы 20 эш көненнән артырга тиеш түгел.

Бер кече эшкуарлык субъектына карата, урынга барып, план буенча тикшерүләр үткәрүнең гомуми срогы кече предприятие өчен – елга 50 сәгатьтән һәм бик кечкенә предприятие өчен унбиш сәгатьтән артык була алмый.

Кече эшкуарлык субъекты булып торучы эш бирүчеләргә карата план буенча урынга барып тикшерү уздырганда, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысасында документлар һәм (яки) мәгълүмат алу зарурлыгы очрагында, тикшерү уздыру министр (министр урынбасары) тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү өчен кирәкле срокка туктатылып торырга мөмкин, ләкин 10 эш көненнән дә артыкка түгел. Тикшерү үткәрүне кабат туктатып тору рөхсәт ителми.

Тикшерү үткәрүне туктатып тору срогы гамәлдә булган чорда кече эшкуарлык субъектының территориясендә, биналарында, төзелмәләрендә, корылмаларында, бүлмәләрендә, бүтән объектларында Министрлыкның вазыйфаи затларының әлеге тикшерүгә бәйле гамәлләре туктатып торыла.

2.3.2. Катлаулы һәм (яки) озакка сузылган тикшеренүләр, сынаулар, махсус экспертизалар, тикшерүләр үткәрү зарурлыгына бәйле гадәттән тыш очракларда, Министрлыкның урынга барып, план буенча тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларының дәлилләнгән тәкъдимнәре нигезендә, урынга барып, план буенча тикшерү үткәрү срогы министр тарафыннан озайтылырга мөмкин, ләкин 20 эш көненнән дә артыкка түгел, кече предприятиеләргә карата – 50 сәгатьтән дә артыкка түгел, бик кечкенә предприятие өчен унбиш сәгатьтән дә артыкка түгел.

2.3.3. Юридик затны, шәхси эшкуарны план буенча тикшерү өч елга бер тапкырдан ешрак уздырылмый.

2.4. Тикшерүләр үткәрү өчен нигезләр.

2.4.1. План буенча тикшерүләр Министрлык тарафыннан төзелә торган еллык планнар нигезендә үткәрелә. Еллык планнар (алга таба – Планнар) № 294-ФЗ Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда прокуратура органнары белән килештерелергә тиеш. Министр тарафыннан расланган Планнар Министрлыкның “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырыла.

2016 елның 1 гыйнварыннан алып 2018 елның 31 декабренә кадәрге чорда,

2007 елның 24 июлендәге “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” № 209-ФЗ Федераль законның 4 статьясы нигезләмәләренә туры китереп, кече эшкуарлык субъектларына кертелгән эш бирүчеләргә карата план буенча тикшерүләр № 294-ФЗ Федераль законның 26.1 статьясы таләпләренә туры китереп оештырыла һәм уздырыла.

План буенча тикшерүне еллык планга кертү өчен нигез булып, өч ел узу тора:

юридик затны, шәхси эшкуарны дәүләт теркәвенә алган көннән;

юридик затны, шәхси эшкуарны план буенча соңгы тикшерү тәмамланган көннән;

юридик зат, шәхси эшкуар шул өлкәдә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органына эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен башкара башлау турында тапшырылган хәбәрнамәгә туры китереп, эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә башлаган көннән, әлеге хәбәрнамәне тапшыруны таләп итүче эшләр башкарган яки хезмәтләр күрсәткән очракта.

2.4.2. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып торалар:

1) мәҗбүри таләпләрнең ачыкланган бозылуын бетерү турында элегрәк бирелгән күрсәтмәнең юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан үтәлү срогы чыгу;

2) түбәндәге фактлар турында Министрлыкка гражданнарның, шул исәптән юридик затларның, шәхси эшкуарларның мөрәҗәгатьләре һәм гаризалары, шулай ук дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүмат керү:

а) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерелү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, Илкүләм китапханә фонды составына керүче аерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга, дәүләт иминлегенә зыян китерелү куркынычы туу, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы барлыкка килү;

б) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерелү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, Илкүләм китапханә фонды составына керүче аерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга, дәүләт иминлегенә зыян китерелү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү;

в) кулланучыларның хокуклары бозылу (хокуклары бозылган гражданнар мөрәҗәгать иткән очракта);

3) Министрның Россия Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте кушуы

буенча һәм прокуратура органына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнар үтәлешенә күзәтчелек кысасында планнан тыш тикшерү үткәрү турында прокурор таләпләре нигезендә чыгарылган боерыгы (әмере).

Министрлыкка мөрәҗәгать иткән затны ачыкларга мөмкинлек бирмәүче мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, югарыда күрсәтелгән фактлар турында мәгълүматлары булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып тора алмый.

Урынга барып, юридик затны, шәхси эшкуарны планнан тыш тикшерү, андый эш бирүчеләр эшчәнлек алып бара торган урындагы прокуратура органы белән килештергәннән соң, Министрлык тарафыннан бу Административ регламентның 2.4.2 пунктының 2 пунктчасындагы “а” һәм “б” пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча үткәрелергә мөмкин.

2.5. Күзәтчелекне һәм контрольлек итүне турыдан-туры башкаручы вазыйфаи затлар

Дәүләт функциясен турыдан-туры башкаручылар булып, Министрлыкның социаль якланмаган категорияләр өчен эш урыннары булдыру бүлегенең һәм Министрлыкның юридик бүлегенең (административ җаваплылыкка тарту турында беркетмәләр төзү өлешендә) вазыйфаи затлары тора.

Юридик затларны, шәхси эшкуарларны тикшерү Министрлыкның социаль якланмаган категорияләр өчен эш урыннары булдыру бүлегенең тикшерү үткәрүгә Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры (алга таба – министр), Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары (алга таба – министр урынбасары) боерыгы (әмере) белән вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлары (алга таба – вазыйфаи затлар) тарафыннан башкарыла.

2.6. № 294-ФЗ Федераль законны бозган өчен юридик затларның, шәхси эшкуарларның җаваплылыгы

№ 294-ФЗ Федераль законның бозылуына юл куйган, тикшерүләр үткәрүгә нигезсез комачаулаучы, тикшерүләр үткәрелүдән качарга тырышучы һәм (яки) мәҗбүри таләпләрнең ачыкланган бозылуын бетерү турында Министрлыкның күрсәтмәләрен билгеләнгән срокта үтәмәүче юридик затлар, аларның җитәкчеләре, башка вазыйфаи затлары яки вәкаләтле вәкилләре, шәхси эшкуарлар, аларның вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законы нигезендә җавап тота.

2.7. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының тикшерү үткәргәндәге җаваплылыгы

2.7.1. Министрлык, аның вазыйфаи затлары, тиңдәшле рәвештә, функцияләрен, хезмәт йөкләмәләрен тиешенчә үтәмәгән, тикшерү үткәргәндә законсыз гамәлләр кылган (гамәл кылмаган) очракта, Россия Федерациясе законы нигезендә җавап тота.

## 3. Юридик затларга, шәхси эшкуарларга куела торган мәҗбүри таләпләр

Юридик затларга, шәхси эшкуарларга куела һәм үтәлеше Министрлык тарафыннан контрольдә тотыла торган мәҗбүри таләпләр исемлеге, аларны

билгеләүче норматив хокукый актлар исемлеге, тикшерү үткәргәндә юридик затларга, шәхси эшкуарларга күрсәтелә торган документлар исемлеге бу Административ регламентка 2 нче кушымтада китерелгән.

## 4. Тикшерү үткәрелгәндә, юридик зат, шәхси эшкуар тапшыра торган документлар

Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларны ирешү өчен юридик зат, шәхси эшкуар тапшыра торган документлар исемлеге, шулай ук андый документларның формаларын раслаучы норматив хокукый актлар бу Административ регламентка 3 нче кушымтада китерелгән.

## 5. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре

Дәүләт функциясе түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

план буенча урынга барып һәм план буенча документларны тикшерүләр үткәрүне планлаштыру һәм әзерләү;

план буенча урынга барып тикшерү үткәрү;

план буенча документларны тикшерү үткәрү;

урынга барып планнан тыш тикшерүләр һәм документларны планнан тыш тикшерүләр үткәрүне әзерләү;

урынга барып планнан тыш тикшерү үткәрү;

документларны планнан тыш тикшерү үткәрү;

тикшерү актында билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуда закон бозылу фактлары булганда, тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча чаралар күрү.

Дәүләт функциясен үтәүнең блок-схемасы бу Административ регламентның 4 нче кушымтасында китерелә.

Дәүләт функциясен үтәүне туктатып тору Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган очракларда рөхсәт ителә.

### 5.1. “План буенча урынга барып һәм план буенча документларны тикшерүләр үткәрүне планлаштыру һәм әзерләү” административ процедурасы

5.1.1. “План буенча урынга барып һәм план буенча документларны тикшерүләр үткәрүне планлаштыру һәм әзерләү” административ процедурасын башлау өчен нигез булып еллык Планны әзерләү һәм аның проектын килештерү өчен прокуратура органнарына җибәрү сроклары килеп җитү тора.

5.1.2. Министрлыкның социаль якланмаган категорияләр өчен эш урыннары булдыру бүлеге начальнигы еллык План әзерләү өчен җаваплы башкаручыны

(җаваплы башкаручыларны) (алга таба – еллык План әзерләү буенча җаваплы башкаручы) билгеләп куя.

Үтәү срогы: план буенча тикшерүләр үткәрү елыннан алдан килгән елның 1 августыннан соңга калмыйча;

5.1.3. План әзерләү буенча җаваплы башкаручы "План буенча урынга барып һәм план буенча документларны тикшерүләр үткәрүне планлаштыру һәм әзерләү" административ процедурасының түбәндәге административ гамәлләрен башкара:

- дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларны, шәхси эшкуарларны план буенча тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләүнең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең № 489 карары белән расланган кагыйдәләре белән күздә тотылган форма буенча еллык План проектын төзи, аны социаль якланмаган категорияләр өчен эш урыннары булдыру бүлеге начальнигы белән, министр һәм министр урынбасары белән килештерә;

үтәү срогы: план буенча тикшерүләр үткәрү елыннан алдан килгән елның 23 августыннан соңга калмыйча;

- план буенча тикшерүләр үткәрү елыннан алдан килгән елның 1 сентябренә кадәр еллык Планның кәгазьдәге проектын, кулга бирү турындагы хәбәрнамә белән заказлы хат итеп почта аша яисә, "Электрон имза турында" Федераль законга туры китереп, көчәйтелгән квалифкацияләнгән электрон имза (алга таба – көчәйтелгән квалифкацияләнгән электрон имза) белән имзаланган электрон документ рәвешендә, килештерү өчен прокуратура органына җибәрә (электрон рәвештәге күчермәсен кушып);

5.1.4. Прокуратура органы еллык план проектын карап тикшергәннән һәм тәкъдимнәр керткәннән соң План әзерләү буенча җаваплы башкаручы:

- прокуратура органыннан кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, еллык план проектына төзәтмәләр кертә;

- кертелгән үзгәрешләре белән еллык план проектын Министрлыкның социаль якланмаган категорияләр өчен эш урыннары булдыру бүлеге начальнигы белән килештерә;

- еллык план проектын министрга раслау өчен җибәрә;

- еллык план министр тарафыннан расланганнан соң, аны кәгазьдә (электрон рәвештәге күчермәсен кушып), кулына тапшыру турындагы хәбәрнамә белән, заказлы хат итеп, яисә көчәйтелгән квалифкацияләнгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә прокуратураның тиешле органына җибәрә.

Үтәү срогы: расланган еллык планны прокуратурага җибәрү – план буенча тикшерүләр үткәрү елыннан алдан килгән елның 1 ноябренә кадәр.

5.1.5. План әзерләү буенча җаваплы башкаручы расланган еллык планны Министрлыкның рәсми сайтына урнаштыруны оештыра.

Үтәү срогы: агымдагы календарь елының 31 декабренә кадәр.

5.1.6. Еллык планга үзгәрешләр кертү раслаучы документлар (юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яки шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт

реестрыннан юридик затны, шәхси эшкуарны дәүләт теркәвенә алу, ябу (реестрдан чыгару) турында язма кертелү хакындагы өземтәләр) булганда, түбәндәге очракларда рөхсәт ителә:

- түбәндәгеләр белән бәйле рәвештә юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлеген планлы тикшерү үткәрү мөмкинлеге булмау:

- юридик затның, шәхси эшкуарның бетерелүе яки үзгәртеп оештырылуы;

- юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлеген туктатуы;

- җиңеп чыга алмаслык көчтәге хәлләр башлану.

Еллык планга үзгәрешләр кертү министр боерыгы белән тормышка ашырыла. Еллык планга кертелгән үзгәрешләр турында мәгълүматлар алар кертелгән көннән алып 3 эш көне эчендә, билгеләнгән тәртиптә, кәгазьдә (электрон рәвештәге күчермәсен кушып), кулына тапшыру турындагы хәбәрнамә белән, заказлы хат итеп, яисә электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә тиешле прокуратура органына җибәрелә һәм үзгәрешләр кертелгән көннән алып 5 эш көне эчендә Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырыла.

5.1.7. Министр, эш бирүчене План нигезендә тикшерү үткәрү өчен, Министрлыкның социаль якланмаган категорияләр өчен эш урыннары булдыру бүлегенең вазыйфаи затлары арасыннан җаваплы башкаручыны (җаваплы башкаручыларны) (алга таба – җаваплы башкаручы) билгеләп куя.

Үтәү срогы: эш бирүчене тикшерү үткәрү башлануга кадәр өч атнадан да соңга калмыйча яисә План төзелгәннән соң ук.

5.1.8. Җаваплы башкаручы “План буенча урынга барып һәм план буенча документларны тикшерүләр үткәрүне планлаштыру һәм әзерләү” административ процедурасының түбәндәге административ гамәлләрен башкара:

- тикшерү үткәрү турында әмернең яки боерыкның РФ Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган типовой формасына туры китереп, тикшерү үткәрү турында боерык (әмер) проектын әзерли, аны үткәрү башлануга кадәр ике атнадан да соңга калмыйча.

Тикшерү үткәрү турында боерыкта (әмердә) түбәндәгеләр күрсәтелә:

Министрлыкның атамасы;

тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затларның, шулай ук тикшерү үткәрүгә чакырылучы экспертларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, вазыйфалары;

тикшерү үткәрелә торган юридик затның атамасы, юридик затның (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) урнашкан урыны яки тикшерү үткәрелә торган шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме, шәхси эшкуарның чынлыкта эшчәнлек алып бару урыннары;

тикшерүнең максатлары, бурычлары, предметы һәм аны үткәрү срогы;

тикшерү үткәрүнең хокукый нигезләре, шул исәптән тикшерелергә тиешле мәҗбүри таләпләр;

тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен зарур контроль чараларын уздыру сроклары һәм аларның исемлеге;

дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентлар исемлеге;

тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат, шәхси эшкуар тапшырырга тиешле документлар исемлеге;

тикшерү үткәрүнең башлану һәм тәмамлану көннәре;

- тикшерү үткәрү турындагы боерыкның (әмернең) министр тарафыннан имзалануын тәэмин итә;

- тикшерү үткәрү башлана торган көнгә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, юридик затның җитәкчесенә, шәхси эшкуарга тикшерү үткәрү турында хәбәрнамә җибәрүне (кулына бирү турында хәбәрнамә белән почта аша заказлы хат итеп яки факсимиль элемтә чараларын кулланып, яки электрон почта аша) тәэмин итә;

бу пунктның үтәлү срогы: өч эш көненнән артык түгел.

5.1.9. Җаваплы башкаручының план буенча урынга барып һәм план буенча документлар тикшерү үткәрүне планлаштыру һәм әзерләү буенча карар кабул итүе критерийлары булып бу Административ регламентның 2.4.1 пунктында күрсәтелгән очраклар тора.

5.1.10. “План буенча урынга барып һәм план буенча документларны тикшерү үткәрүне планлаштыру һәм әзерләү” административ процедурасы нәтиҗәсе булып юридик затның җитәкчесенә, шәхси эшкуарга түбәндәгеләрне җибәрү тора:

план буенча урынга барып тикшерү үткәргәндә – план буенча урынга барып тикшерү үткәрү турындагы боерыкның (әмернең) күчермәсен кушып, тикшерү үткәрү турында хәбәрнамә (тикшерү үткәрү турындагы әмернең яки боерыкның РФ Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган типовой формасы нигезендә);

план буенча документларны тикшерү үткәргәндә – юридик затның, шәхси эшкуарның план буенча документларны тикшерү үткәрү өчен кирәкле материаллар һәм документларны бирүен сорап рәсми мөрәҗәгать.

5.1.11. “План буенча урынга барып һәм план буенча документларны тикшерү үткәрүне планлаштыру һәм әзерләү” административ процедурасы үтәлешенең нәтиҗәсен теркәү бу Административ регламентның 5.1.10 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамә, боерык (әмер) яки рәсми мөрәҗәгатьнең күчермәләрен исәпкә алу һәм эш материалларында саклау, шулай ук Министрлыкта делопроизводствоны алып бару кагыйдәләренә туры китереп, билгеләнгән тәртиптә бу документларны электрон рәвештә аерым саклау юлы белән башкарыла.

## 5.2. “План буенча урынга барып тикшерү үткәрү” административ процедурасы

5.2.1. “План буенча урынга барып тикшерү үткәрү” административ процедурасын башлау өчен нигез булып, кирәкле юридик затны, шәхси эшкуарны Министрлыкның юридик затларны, шәхси эшкуарларны тикшерү үткәрү буенча еллык Планына кертү, шулай ук документларын тикшергәндә түбәндәгеләр мөмкин булмау:

юридик затның, шәхси эшкуарның эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен алып бара башлау турындагы хәбәрнамәсендәге һәм Министрлык карамагында булган бүтән документларындагы мәгълүматларның тулылыгына һәм дөреслеккә туры килүенә инану;

контроль буенча тиешле чараны үткәрмәгән килеш, юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлегенең мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяләү.

5.2.2. Җаваплы башкаручы “План буенча урынга барып тикшерү үткәрү” административ процедурасының түбәндәге административ гамәлләрен башкара:

- юридик затка, шәхси эшкуар янына Министрлык боерыгы (әмере) белән билгеләнгән срокта килә, эш буенча куллана торган таныклыгын күрсәтә һәм юридик затның җитәкчесенә, шәхси эшкуарга тикшерү үткәрү турындагы боерыкның (әмернең) күчермәсен бирә, юридик затның җитәкчесенә, шәхси эшкуарга тикшерү үткәрү максатлары, бурычлары, нигезләре, контроль чараларының төрләре һәм күләме, аны үткәрүнең сроклары һәм шартлары турында мәгълүмат бирә;

үтәү срогы: юридик затка, шәхси эшкуар янына килгәч үк;

- документларда булган, тикшерүнең максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле мәгълүматларны өйрәнә;

- юридик затның, шәхси эшкуарның түбәндәге нигезләмәләрне (бу Административ регламентның 2 нче кушымтасына туры китереп, тикшерү вакытында эш бирүчеләргә куела торган мәҗбүри таләпләрне) үтәвен тикшерә:

инвалидларны эшкә алу өчен билгеләп куелган квота нигезендә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен булдырылган яки бүлеп бирелгән эш урыннары санының халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасы булдыру өлкәсендәге законнар таләпләренә туры килүен;

чынлыкта эшләүче инвалидлар санының инвалидларны эшкә алу өчен исәпләнгән эш урыннары санына туры килүен;

юридик затның, шәхси эшкуарның халык мәшгульлеге үзәгенә инвалидларны һөнәри тернәкләндерү һәм аларның эшкә урнашуына ярдәм итү буенча эшчәнлекне башкару өчен кирәкле мәгълүматны билгеләнгән срокларда тапшыруының тулылыгын һәм дөреслеккә туры килүен;

юридик затның, шәхси эшкуарның халык мәшгульлеге үзәгенә инвалидларны эшкә алу өчен квота үтәлеше турындагы мәгълүматны билгеләнгән срокларда тапшыруының тулылыгын һәм дөреслеккә туры килүен;

- зарурлык булганда, план буенча урынга барып тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча документлар һәм материалларны, шулай ук юридик затның җитәкчесенең, шәхси эшкуарның язмача аңлатмаларын сорап ала, тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча юридик затның җитәкчесе һәм/яки хезмәткәрләре, шәхси эшкуар белән әңгәмәләр үткәрә;

- тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча тапшырылган документлар, материаллар һәм аңлатмаларны анализлый һәм халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасы булдыру өлкәсендә закон бозуларның булуы (булмавы) турында карар кабул итә;

- закон бозу фактлары ачыкланганда:

закон бозу фактларын дәлилләүче документларны (алга таба – дәлилләүче документлар) әзерли һәм күчермәләрен билгеләнгән тәртиптә раслый;

халык мәшгульлеге турындагы закон бозылу фактлары турында мәгълүматны, дәлилләүче документларның күчермәләрен кушып, тикшерү акты проектына кертә;

- үткәрелгән тикшерү турында Министрлык атамасы, тикшерү үткәрүнең башлану һәм тәмамлану көннәре, аны үткәрүнең вакыты, тикшерүнең хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм предметы, ачыкланган закон бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турындагы мәгълүматлар кергән язманы, тикшерү үткәрүче вазыйфаи затның яки вазыйфаи затларның фамилиясен, исемен, атасының исемен һәм вазыйфасын күрсәтеп, аның яки аларның имзаларын тикшерүләрне исәпкә алу журналына кертә;

- эш бирүчедә тикшерүләрне исәпкә алу журналы булмаганда, тиешле язманы тикшерү акты проектына кертә;

- тикшерү акты проектын әзерли (тикшерү актының типовой формасы РФ Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган), шуңа тикшерү үткәргәндә юридик затның җитәкчесе, шәхси эшкуар тапшырган документларның исемлеген һәм күчермәләрен (алга таба – кушымталар) өсти, тикшерү акты проектын тикшерү үткәрүгә җаваплы вазыйфаи затка карап тикшерү өчен тапшыра;

үтәү срогы: тикшерү тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә;

- тикшерү актын ике нөсхәдә имзалый;

үтәү срогы: акт төзелгәннән соң бер эш көне эчендә;

- кушымталарның күчермәләре белән бергә тикшерү актының бер нөсхәсен, танышканлыгы турында кул куйдырып, юридик затның җитәкчесенә, шәхси эшкуарга бирә, яки тикшерү актын әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә җибәрә (тикшерелүче затның дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысасында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булганда);

үтәү срогы: акт имзаланганнан соң бер эш көне эчендә;

- юридик затның җитәкчесе, шәхси эшкуар шунда булмаган очракта, шулай ук тикшерелүче затның тикшерү акты белән танышканлыгы турында расписка бирүдән баш тарткан, яисә тикшерү акты белән танышудан баш тарткан очракта, тикшерү актын кулга бирү турында хәбәрнамә белән заказлы хат итеп почта аша җибәрүне тәэмин итә;

үтәү срогы: акт имзаланганнан соң бер эш көне эчендә;

- тикшерү актының икенче нөсхәсенә бу хакта язып куя, почта аша җибәрелгән заказлы хатны кулга бирү турындагы хәбәрнамәне һәм (яки) тикшерү актының алынуына бүтән дәлилне шунда өсти;

үтәү срогы: тикшерү актын заказлы хат итеп почта аша җибәргәннән соң бер эш көне эчендә;

- юридик затның җитәкчесе, шәхси эшкуар тикшерү актының эчтәлеге белән килешмәгән очракта, юридик затның җитәкчесенең, шәхси эшкуарның язмача ризасызлыгын тикшерү актына өсти;

үтәү срогы: юридик затның җитәкчесенең, шәхси эшкуарның ризасызлыкларын алганнан соң бер эш көне эчендә;

- тикшерү актында халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендә закон бозылу фактлары булганда, бу Административ регламентның 5.7.2 пункты белән күздә тотылган административ процедураларны (гамәлләрне) башкара.

5.2.3. Җаваплы башкаручының план буенча урынга барып тикшерү үткәрүнең нәтиҗәләре буенча карар кабул итүенең критерийлары булып тикшерү вакытында тапшырылган документлар һәм материалларның халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендәге законга туры килүе (туры килмәве) тора.

5.2.4. “План буенча урынга барып тикшерү үткәрү” административ процедурасының нәтиҗәсе булып юридик затның, шәхси эшкуарның халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендә ачыкланган закон бозулары яисә аларның булмавы тора.

5.2.5. “План буенча урынга барып тикшерү үткәрү” административ процедурасының нәтиҗәсе тикшерү актында, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында электрон рәвештә теркәлә.

5.2.6. “План буенча урынга барып тикшерү үткәрү” административ процедурасының үтәлү срогы – 20 эш көненнән артык түгел.

### 5.3. “План буенча документларны тикшерү үткәрү” административ процедурасы

5.3.1. “План буенча документларны тикшерү үткәрү” административ процедурасын башлау өчен нигез булып кирәкле юридик затны, шәхси эшкуарны еллык Планга кертү тора. План Министрлыкның “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырыла.

5.3.2. Җаваплы башкаручы “План буенча документларны тикшерү үткәрү” административ процедурасының түбәндәге административ гамәлләрен башкара:

- юридик затның, шәхси эшкуарның Министрлык карамагында булган материалларын һәм документларын, моннан алдагы тикшерүләр актларын, административ хокук бозулар турындагы эшләрне карап тикшерү материалларын һәм бу юридик затка, шәхси эшкуарга карата, аларның билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуына башкарылган күзәтчелек һәм контроль нәтиҗәләре турындагы башка документларны өйрәнә;

- Министрлык карамагында булган документлардагы мәгълүматларның дөреслеккә туры килүе нигезле шик уяткан яисә бу мәгълүматлар юридик затның, шәхси эшкуарның халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендәге законның мәҗбүри таләпләрен үтәвен бәяләргә мөмкинлек бирмәгән очракта, юридик зат адресына, шәхси эшкуар адресына, документларын тикшерү үткәрү барышында карап тикшерү өчен кирәкле башка документларны тапшыруын таләп итеп, рәсми мөрәҗәгать җибәрә (кулына бирү турында хәбәрнамә белән почта аша заказлы хат итеп яки

факсимиль элемтә чараларын кулланып, яки электрон почта аша), рәсми мөрәҗәгатькә тикшерү үткәрү турындагы боерыкның (әмернең) мөһер белән расланган күчермәсен дә өсти;

- оешмадан кергән материаллар һәм документларны өйрәнүгә нигезләнеп, халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендә закон бозылуның булуы (булмавы) турында, юридик затның, шәхси эшкуарның түбәндәге нигезләмәләрне үтәвен тикшерү максаты белән, карар кабул итә:

- инвалидларны эшкә алу өчен билгеләп куелган квота нигезендә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен булдырылган яки бүлеп бирелгән эш урыннары санының халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендәге закон таләпләренә туры килүен;

- чынлыкта эшләүче инвалидлар санының инвалидларны эшкә алу өчен исәпләнгән эш урыннары санына туры килүен;

- юридик затның, шәхси эшкуарның халык мәшгульлеге үзәгенә инвалидларны һөнәри тернәкләндерү һәм аларның эшкә урнашуына ярдәм итү буенча эшчәнлекне башкару өчен кирәкле мәгълүматны билгеләнгән срокларда тапшыруының тулылыгын һәм дөреслеккә туры килүен;

- юридик затның, шәхси эшкуарның халык мәшгульлеге үзәгенә инвалидларны эшкә алу өчен квота үтәлеше турындагы мәгълүматны билгеләнгән срокларда тапшыруының тулылыгын һәм дөреслеккә туры килүен;

- тикшерү акты проектын әзерли, аңа кушымталарны өсти, тикшерү акты проектын тикшерү үткәрүгә җаваплы вазыйфаи затка карап тикшерү өчен тапшыра;

үтәү срогы: тикшерү тәмамланганнан соң ук;

- тикшерү актын ике нөсхәдә имзалый;

үтәү срогы: акт рәсмиләштерелгәннән соң ук;

- тикшерү актының бер нөсхәсен, танышып чыгу өчен, юридик затның җитәкчесенә, шәхси эшкуарга җибәрә (кулына бирү турында хәбәрнамә белән почта аша заказлы хат итеп яки факсимиль элемтә чараларын кулланып, яки электрон почта аша);

үтәү срогы: акт рәсмиләштерелгәннән һәм имзаланганнан соң ук;

- тикшерү актына почта аша җибәрелгән заказлы хатны кулына бирү турында хәбәрнамәне һәм (яки) актның алынуына бүтән дәлилне, шулай ук юридик затның җитәкчесе, шәхси эшкуар тикшерү акты эчтәлеге белән килешмәгән очракта, юридик затның җитәкчесенең, шәхси эшкуарның язмача ризасызлыгын (булганда) өсти;

үтәү срогы: юридик затның җитәкчесенең, шәхси эшкуарның ризасызлыкларын алганнан соң ук;

- тикшерү актында халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендәге закон бозылу фактлары булганда, бу Административ регламентның 5.7.2 пункты белән күздә тотылган административ процедураларны (гамәлләрне) башкара.

5.3.3. Җаваплы башкаручының план буенча документларны тикшерү

үткәрүнең нәтиҗәләре буенча карар кабул итүенең критерийлары булып тикшерү вакытында тапшырылган документлар һәм материалларның халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендәге законга туры килүе (туры килмәве) тора.

5.3.4. “План буенча документларны тикшерү үткәрү” административ процедурасының нәтиҗәсе булып юридик затның, шәхси эшкуарның халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендә законны бозуын ачыклау яисә бозуларның булмавы тора.

5.3.5. “План буенча документларны тикшерү үткәрү” административ процедурасының нәтиҗәсе тикшерү актында, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында электрон рәвештә теркәлә.

5.3.6. “План буенча документларны тикшерү үткәрү” административ процедурасының үтәлү срогы – 20 эш көненнән артык түгел.

### 5.4. “Планнан тыш урынга барып һәм планнан тыш документларны тикшерүләр үткәрүне әзерләү” административ процедурасы

5.4.1. “Планнан тыш урынга барып һәм планнан тыш документларны тикшерүләр үткәрүне әзерләү” административ процедурасын башлау өчен нигезләр булып бу Административ регламентның 2.4.2 пунктында күрсәтелгән очраклар тора.

5.4.2. Министр тикшерү үткәрү турында карар кабул итә һәм Министрлыкның социаль якланмаган категорияләр өчен эш урыннары булдыру бүлеге начальнигына тикшерү үткәрүне йөкли.

Үтәү срогы: планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигезләр барлыкка килгән көннән башлап бер эш көне эчендә.

5.4.3. Министр, оешманы тикшерү үткәрү өчен, Министрлыкның социаль якланмаган категорияләр өчен эш урыннары булдыру бүлегенең вазыйфаи затлары арасыннан җаваплы башкаручыны (башкаручыларны) (алга таба – җаваплы башкаручы) билгели.

Үтәү срогы: планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигезләр барлыкка килгән көннән башлап бер эш көне эчендә.

5.4.4. Җаваплы башкаручы “Планнан тыш урынга барып һәм планнан тыш документларны тикшерүләр үткәрүне әзерләү” административ процедурасының түбәндәге административ гамәлләрен башкара:

1) тикшерү үткәрү турында министр тарафыннан карар кабул ителгәннән соң ике көнлек срокта тикшерү үткәрү турында боерык (әмер) (тикшерү үткәрү турындагы боерыкның (әмернең) типовой формасы РФ Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган) проектын әзерли;

үтәү срогы: ике эш көненнән артык түгел;

2) тикшерү үткәрү турындагы боерыкның (әмернең) министр тарафыннан имзалануын тәэмин итә;

үтәү срогы: ике эш көненнән артык түгел;

3) Россия Федерациясе законы белән күздә тотылган очракларда планнан

тыш урынга барып тикшерүне әзерләгәндә:

- тикшерү үткәрү турындагы боерык (әмер) имзаланган көнне, аның күчермәсен һәм тикшерү үткәрү өчен нигез булып торган мәгълүматлар кергән документларны кушып, оешма эшчәнлек алып бара торган урындагы прокуратура органына планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрүне килештерү турында гариза (планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрүне прокуратура органы белән килештерү турындагы гаризаның типовой формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган) тапшыра яисә аны кулга бирү турында хәбәрнамә белән почта аша заказлы хат итеп яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрә;

үтәү срогы: тикшерү үткәрү турындагы боерык (әмер) имзаланган көнне;

- планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрүне килештерү турында прокуратура органы карарын ала;

4) Министрлыкка гражданнарның, шул исәптән шәхси эшкуарларның, юридик затларның мөрәҗәгатьләре, гаризалары, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерелү (зыян китерелү куркынычы туу), хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, Илкүләм китапханә фонды составына керүче аерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга, дәүләт куркынычсызлыгына зыян китерелү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү (куркынычы янау), шулай ук кулланучыларның хокуклары бозылу (хокуклары бозылган гражданнар мөрәҗәгать иткән очракта) фактлары турында мәгълүмат керү нигезе буенча үткәрелгән планнан тыш урынга барып тикшерүдән тыш, җаваплы башкаручы юридик затның җитәкчесенә, шәхси эшкуарга планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрү турында тикшерү башлануга егерме дүрт сәгатьтән дә ким булмаган вакыт кала, мөмкин булган теләсә нинди алым белән хәбәр итә.

5.4.5. Җаваплы башкаручының планнан тыш урынга барып һәм планнан тыш документларны тикшерүләр үткәрүгә әзерлек буенча карар кабул итүенең критерие булып бу Административ регламентның 2.4.2 пунктында күрсәтелгән очракларның булуы тора.

5.4.6. "Планнан тыш урынга барып һәм планнан тыш документларны тикшерүләр үткәрүне әзерләү" административ процедурасының нәтиҗәсе булып юридик затның җитәкчесенә, шәхси эшкуарга түбәндәгеләрне җибәрү тора:

планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрүгә әзерлек вакытында – планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрү турындагы боерыкның (әмернең) күчермәсен кушып, тикшерү үткәрү турында хәбәрнамә җибәрү (тикшерү үткәрү турындагы боерыкның (әмернең) РФ Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган типовой формасына туры китереп);

планнан тыш документларны тикшерү үткәрүгә әзерлек вакытында – эш бирүченең планнан тыш документларны тикшерү үткәрү өчен кирәкле материалларны һәм документларны бирүен сорап рәсми мөрәҗәгать.

5.4.7. “Планнан тыш урынга барып һәм планнан тыш документларны тикшерүләр үткәрүне әзерләү” административ процедурасы үтәлешенең нәтиҗәсен теркәү бу Административ регламентның 5.4.6 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамә, боерык (әмер) яки рәсми мөрәҗәгатьнең күчермәләрен исәпкә алу һәм эш материалларында саклау, шулай ук Министрлыкта делопроизводствоны алып бару кагыйдәләренә туры китереп, билгеләнгән тәртиптә бу документларны электрон рәвештә аерым саклау юлы белән башкарыла.

5.5. “Планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрү” административ процедурасы

5.5.1. “Планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрү” административ процедурасын башлау өчен нигез булып бу Административ регламентның 2.4.2 пунктында күрсәтелгән очраклар барлыкка килү, андый эш бирүче эшчәнлек алып бара торган урындагы прокуратура органы белән килештерү, “Планнан тыш урынга барып һәм планнан тыш документларны тикшерүләр үткәрүне әзерләү” административ процедурасының тәмамлануы тора.

5.5.2. Җаваплы башкаручы “Планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрү” административ процедурасының түбәндәге административ гамәлләрен башкара:

бу Административ регламентның 5.5.2 пунктының 2, 4, 5 абзацлары белән күздә тотылган административ гамәлләрне башкара;

тикшерүнең максатлары, бурычлары һәм предметына бәйле документларында булган мәгълүматларны өйрәнә һәм нигезләргә бәйле рәвештә тикшерә:

эш бирүченең мәҗбүри таләпләрнең һәм (яки) Татарстан Республикасы хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләрнең ачыкланган бозылуын бетерү турында элегрәк бирелгән күрсәтмәне үтәвен;

гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерелүне, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, Илкүләм китапханә фонды составына керүче аерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга, дәүләт куркынычсызлыгына зыян китерелүне булдырмау буенча, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр чыгуны кисәтү буенча, андый зыян китерелүнең нәтиҗәләрен бетерү буенча чаралар күрүен;

Министрлыкка гражданнарның, шул исәптән шәхси эшкуарларның, юридик затларның мөрәҗәгатьләрендә, гаризаларында, кулланучыларның хокуклары бозылу (билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидны эшкә алудан нигезсез баш тарту) турында дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан,

массакүләм мәгълүмат чараларыннан кергән мәгълүматта бәян ителгән фактларны;

прокуратура органнарына кергән материалларда һәм мөрәҗәгатьләрдә бәян ителгән фактларны;

- бу Административ регламентның 5.5.2 пунктының 12 – 29 абзацлары белән күздә тотылган административ гамәлләрне башкара;

- тикшерү акты күчермәсен, ул имзаланган көннән алып 5 эш көне эчендә, планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрүне килештерү турында карар кабул иткән прокуратура органына җибәрә;

- тикшерү актында халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендәге закон бозылу фактлары булганда, бу Административ регламентның 5.7.2 пункты белән күздә тотылган административ процедураларны (гамәлләрне) башкара.

5.5.3. Җаваплы башкаручының планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрүнең нәтиҗәләре буенча карар кабул итүенең критерийлары булып тикшерү вакытында тапшырылган документлар һәм материалларның халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендәге законга туры килүе (туры килмәве) тора.

5.5.4. "Планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрү" административ процедурасының нәтиҗәсе булып юридик затның, шәхси эшкуарның халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендә законны бозуын ачыклау яисә бозуларның булмавы тора.

5.5.5. "Планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрү" административ процедурасының нәтиҗәсе тикшерү актында, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында электрон рәвештә теркәлә.

5.5.6. "Планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрү" административ процедурасының үтәлү срогы – 20 эш көненнән артык түгел.

### 5.6. "Планнан тыш документларны тикшерү үткәрү" административ процедурасы

5.6.1. "Планнан тыш документларны тикшерү үткәрү" административ процедурасын башлау өчен нигез булып бу Административ регламентның 2.4.2 пунктында күрсәтелгән очраклар барлыкка килү һәм "Планнан тыш урынга барып һәм планнан тыш документларны тикшерүләр үткәрүне әзерләү" административ процедурасының тәмамлануы тора.

5.6.2. Җаваплы башкаручы "Планнан тыш документларны тикшерү үткәрү" административ процедурасының түбәндәге административ гамәлләрен башкара:

- бу Административ регламентның 5.5.2 пунктының 3 – 10 абзацлары белән күздә тотылган административ гамәлләрне башкара;

- бу Административ регламентның 5.3.2 пунктының 2 – 9, 11, 13, 15 абзацлары белән күздә тотылган административ гамәлләрне башкара;

- тикшерү актында халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендәге закон бозылу фактлары булганда, бу

Административ регламентның 5.7.2 пункты белән күздә тотылган административ процедураларны (гамәлләрне) башкара.

5.6.3. Җаваплы башкаручының планнан тыш документларны тикшерү үткәрүнең нәтиҗәләре буенча карар кабул итүенең критерийлары булып тикшерү вакытында тапшырылган документлар һәм материалларның халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендәге законга туры килүе (туры килмәве) тора.

5.6.4. “Планнан тыш документларны тикшерү үткәрү” административ процедурасының нәтиҗәсе булып юридик затның, шәхси эшкуарның халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендә законны бозуын ачыклау яисә бозуларның булмавы тора.

5.6.5. “Планнан тыш документларны тикшерү үткәрү” административ процедурасының нәтиҗәсе тикшерү актында, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында электрон рәвештә теркәлә.

5.6.6. “Планнан тыш документларны тикшерү үткәрү” административ процедурасының үтәлү срогы – 20 эш көненнән артык түгел.

### 5.7. Тикшерү актында халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендәге закон бозылу фактлары булганда, тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча чаралар күрү

5.7.1. “Тикшерү актында халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендәге закон бозылу фактлары булганда, тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча чаралар күрү административ процедурасын башлау өчен нигез булып, тикшерү актында булган халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендә закон бозылу фактлары тора.

5.7.2. Җаваплы башкаручы түбәндәге административ процедураларны (гамәлләрне) башкара:

үтәлүе мәҗбүри булган, халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендә закон бозылуны бетерү турындагы күрсәтмәне (үрнәк формасы – бу Административ регламентның 5 нче кушымтасында) һәм (яки) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерелүне, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, Илкүләм китапханә фонды составына керүче аерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга, дәүләт куркынычсызлыгына, физик һәм юридик затларның милкенә, дәүләтнеке яки муниципаль милеккә зыян китерелүне булдырмау, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр чыгуны кисәтү буенча чаралар, шулай ук федераль законнар белән күздә тотылган башка төрле чаралар күрү турында күрсәтмәне әзерли һәм бирә;

үтәү срогы: тикшерү тәмамланганнан соң ук, тикшерү актын төзү белән бер үк вакытта;

- ачыкланган бозуларны бетерүне, аларны кисәтүне, гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә ихтимал зыян китерелүне, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, Илкүләм китапханә фонды составына керүче аерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга, дәүләт куркынычсызлыгына зыян китерелүне булдырмауны, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр чыгуны кисәтүне контрольдә тоту буенча чаралар күрә;

Тикшерү акты имзаланганнан соң килүче көннән дә соңга калмыйча, Министрлыкның юридик бүлегенә, тикшерү үткәргәндә, эш бирүченең билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә кабул итү буенча үз бурычларын үтәмәгәнлеге ачыклану турында, тикшерү актының расланган күчермәсен, эш бирүченең тикшерү акты белән танышканлыгын раслаучы документларны һәм тикшерү үткәргәндә ачыкланган бозуларны раслаучы бүтән материалларны кушып, хезмәт итү запискасы җибәрә (тапшыра);

үтәү срогы: әлеге очракларны кисәтү, булдырмый калу – бозулар ачыкланганнан соң ук; бетерүне контрольдә тоту – бетерү чоры дәвамында.

5.7.3. Министрлыкның юридик бүлегенең вазыйфаи заты түбәндәге административ гамәлләрне башкара:

- тапшырылган материалларны карап, РФ АХБКның 5.42 статьясының 1 өлеше белән күздә тотылган административ хокук бозу вакыйгасы барлыгын күрсәтүче җитәрлек мәгълүматлар булуны тикшерә;

- РФ АХБКның 5.42 статьясының 1 өлеше белән күздә тотылган административ хокук бозу вакыйгасы барлыгын күрсәтүче җитәрлек мәгълүматлар булганда, административ хокук бозу турында аңа карата эш кузгатыла торган юридик затның җитәкчесенә, шәхси эшкуарга административ хокук бозу турында беркетмәнең күчермәсен җибәрүне (кулына тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы хат итеп почта аша яки факсимиль элемтә чараларыннан файдаланып, яки электрон почта аша), административ хокук бозу вакыйгасы барлыгы, административ хокук бозу хакында беркетмә төзүнең көне һәм урыны турында хәбәр бирүне тәэмин итә;

үтәү срогы: Министрлыкның социаль якланмаган категорияләр өчен эш урыннары булдыру бүлеге бу Административ регламентның 5.7.2 пункты белән билгеләнгән документлар һәм материалларны тапшырган көннән алып өч эш көненнән артык түгел;

- административ хокук бозу турында аңа карата эш кузгатыла торган юридик затның җитәкчесенә, шәхси эшкуарга хәбәр итү язуында административ хокук бозу турында беркетмә төзү көне буларак күрсәтелгән көнне, әгәр “дело”ның шартларын яисә эшкуар турындагы мәгълүматларны, яки юридик затның җитәкчесе турындагы белешмәләрне өстәмә ачыклау таләп ителмәсә, РФ

АХБКның 5.42 статьясының 1 өлеше белән күздә тотылган административ хокук бозу турында беркетмә төзи. Административ хокук бозу турында беркетмә төзегәндә, административ хокук бозу турында аларга карата эш кузгатыла торган юридик затның җитәкчесенә, шәхси эшкуарга, шулай ук эш буенча тикшерүдә башка катнашучыларга аларның шушы РФ АХБК белән күздә тотылган хокуклары һәм бурычлары аңлатыла, шул хакта беркетмәгә язып куела. Административ хокук бозу турында аңа карата эш кузгатылган шәхси эшкуарга, юридик затның җитәкчесенә административ хокук бозу турында беркетмә белән танышу мөмкинлеге бирелергә тиеш. Әлеге затлар беркетмәнең эчтәлеге буенча аңлатмалар һәм искәртмәләр бирергә хокуклы, алар беркетмәгә өстәп куела. Эшкуар яки юридик затның җитәкчесе административ хокук бозу турында беркетмәне имзалаудан баш тартса, беркетмәгә шул хакта язма кертә. Административ хокук бозу турында беркетмәнең күчермәсе беркетмә төзелгән затка кичекмәстән бирелә.

Административ хокук бозу турында аларга карата эш алып барыла торган эшкуар яки юридик затның җитәкчесе, әгәр аларга билгеләнгән тәртиптә хәбәр ителгән булып та килмәсәләр, административ хокук бозу турында беркетмә алардан башка гына төзелә;

- административ хокук бозу турында беркетмә төзү өчен ул килмәгән очракта, эшкуарга яки юридик затның җитәкчесенә административ хокук бозу турында беркетмәнең күчермәсен (кулына тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы хат итеп почта аша яки факсимиль элемтә чараларыннан файдаланып, яки электрон почта аша) 3 көн эчендә җибәрүне тәэмин итә;

үтәү срогы: беркетмә төзелгән көннән алып өч эш көненнән артык түгел;

- административ хокук бозу турында беркетмәне, административ хокук бозу турындагы эшне карап тикшерү өчен, кулына тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы хат итеп почта аша җибәрүне тәэмин итә;

үтәү срогы: беркетмә төзелгән көннән алып өч эш көненнән артык түгел;

- административ хокук бозу турында беркетмәнең эчтәлеге буенча аңлатмалар яки искәртмәләрне, үзенә карата административ хокук бозу турында эш кузгатылган эшкуардан яки юридик затның җитәкчесеннән беркетмәгә ризасызлык кергән очракта, административ хокук бозу турындагы эшне тикшерә торган гомуми юрисдикция судына билгеләнгән тәртиптә җибәрүне тәэмин итә;

үтәү срогы: административ хокук бозу турында беркетмәнең эчтәлеге буенча аңлатмалар яки искәртмәләр кергән көннән алып өч эш көненнән артык түгел;

- административ хокук бозу турында беркетмәнең күчермәсен тикшерү материалларына кушып куя;

үтәү срогы: административ хокук бозу турында беркетмә (беркетмәнең эчтәлеге буенча аңлатмалар яки искәртмәләр) гомуми юрисдикция судына җибәрелгәннән соң бер эш көне эчендә.

5.7.4. Планнан тыш тикшерү нәтиҗәләре буенча бирелгән күрсәтмә эш бирүче тарафыннан ике айлык срокта үтәлмәгән очракта, җаваплы башкаручы күрсәтмәне үтәү срогы беткәннән соң 5 эш көне эчендә, гаепле затларны РФ

АХБКның 19.5 статьясының 1 өлеше нигезендә административ җаваплылыкка тарту өчен нигезләр булуын раслаучы документлар һәм материалларны кушып, хезмәт итү запискасын әзерли һәм Министрлыкның юридик бүлегенә җибәрә.

Үтәү срогы: күрсәтмәне үтәү срогы беткәннән соң 5 эш көне эчендә.

5.7.5. Бу Административ регламентның 5.7.4 пунктына туры килүче материаллар кергәч, Министрлыкның юридик бүлегенең вазыйфаи заты бу Административ регламентның 5.7.3 пункты белән билгеләнгән административ гамәлләргә охшаш административ гамәлләрне башкара.

5.7.6. Җаваплы башкаручы Министрлыкка юридик зат җитәкчесеннән, шәхси эшкуардан түбәндәгеләр турында мәгълүмат керүен контрольдә тота:

тикшерүләр барышында халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендә ачыкланган закон бозылуларны бетерү;

халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендә җибәрелгән закон бозылуны бетерү турында күрсәтмәне үтәү.

5.7.7. Тикшерү үткәрүнең нәтиҗәләре буенча чаралар күрү буенча карар кабул итүенең критерие булып, тикшерү актында халык мәшгульлегенә булышу һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендә закон бозылу фактлары булганда, халык мәшгульлегенә булышу һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендә тикшерү актында булган закон бозу фактлары тора.

5.7.8. “Тикшерү актында халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендәге закон бозылу фактлары булганда, тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча чаралар күрү” административ процедурасының нәтиҗәсе булып, халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендә җибәрелгән закон бозылуны бетерү турында үтәлүе мәҗбүри булган күрсәтмә тора.

5.7.9. “Тикшерү актында халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендәге закон бозылу фактлары булганда, тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча чаралар күрү” административ процедурасы үтәлүнең нәтиҗәсе халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендә җибәрелгән закон бозылуны бетерү турындагы күрсәтмәгә һәм/яки административ хокук бозу турында беркетмәгә теркәп куела.

## 6. Дәүләт функциясен үтәүне контрольдә тотуның тәртибе һәм формалары

6.1. Министрлык вазыйфаи затларның үз хезмәт бурычларын үтәвен контрольдә тота, вазыйфаи затларның тикшерүләр үткәрү барышында үз вәкаләтләрен тиешенчә үтәмәү очракларының исәбен алып бара, эш урынында тиешле тикшерүләр үткәрә һәм Россия Федерациясе законына туры китереп, андый вазыйфаи затларга карата чаралар күрә.

6.2. Бу Административ регламентның үтәлеше министр тарафыннан

контрольдә тотыла.

6.3. Министрлыкның вазыйфаи затларының бу Административ регламент нигезендә дәүләт күзәтчелеген һәм контролен башкару буенча гамәлләрнең срокларын, эзлеклелеген үтәвенә, аларның карарлар кабул итүенә агымдагы контрольлек министр урынбасары, Министрлыкның социаль якланмаган категорияләр өчен эш урыннары булдыру бүлеге һәм Министрлыкның юридик бүлеге (административ җаваплылыкка тарту турында беркетмәләр төзү өлешендә) начальниклары һәм Министрлыкның вәкаләтле хезмәткәрләре тарафыннан башкарыла.

6.4. Министрлыкның дәүләт функциясен үтәүгә агымдагы контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле хезмәткәрләре исемлеге, әлеге контрольне гамәлгә ашыруның тәртибе һәм ешлыгы Министрлык актлары белән гамәлгә кертелә. Министрлык хезмәткәрләренең агымдагы контрольне башкару вәкаләтләре Министрлыкның структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләрдә, хезмәткәрләрнең вазыйфа регламентларында билгеләнә.

6.5. Агымдагы контроль бу Административ регламентның нигезләмәләре һәм дәүләт функциясен үтәүгә карата таләпләрне билгеләүче бүтән норматив хокукый актлар үтәлүне тикшерүләр үткәрү юлы белән башкарыла. Тикшерүләр үткәрүнең тулылыгына һәм сыйфатына агымдагы контроль даими рәвештә алып барыла һәм гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылуны тикшерүне, ачыклауны һәм билгеләүне, андый закон бозуларны бетерү турында карарлар кабул итүне үз эченә ала.

6.6. Дәүләт функциясен үтәүгә контроль план буенча һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрүне үз эченә ала.

Дәүләт функциясен үтәүнең тулылыгын һәм сыйфатын план буенча тикшерүләр Министрлыкның агымдагы елга еллык эш планы нигезендә үткәрелә. План буенча тикшерүләр әлеге планга министрның күзәтчелек һәм контроль мәсьәләләре белән шөгыльләнүче урынбасары тарафыннан кертелә.

Планнан тыш тикшерүләр элегрәк ачыкланган закон бозуларның бетерелүен тикшерүгә бәйле рәвештә, шулай ук үз вазыйфаи бурычларын үтәгәндә Министрлыкның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр нигезендә үткәрелә.

6.7. Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт функциясен, хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәгән, Россия Федерациясе законы нигезендә тикшерү үткәргәндә законсыз гамәлләр кылган (гамәл кылмаган) өчен җавап тота.

Министрлыкның вазыйфаи затларының дәүләт функциясен үтәү барышында алар тарафыннан кабул ителә (кылына) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен дисциплинар җаваплылыгы чикләре аларның вазыйфаларына кагылышлы регламентлар белән билгеләп куела.

Россия Федерациясе законын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында, андый чаралар күрелгән көннән башлап ун көн эчендә, хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган эш бирүчегә Министрлык язмача хәбәр итәргә тиеш.

6.8. Дәүләт функциясен үтәүгә гражданнар, аларның берләшмәләре һәм

оешмалары ягыннан контроль берләшмәләр һәм оешмаларның уставларына туры китереп башкарыла. Билгеләп куелган вәкаләте чикләрендә Министрлык гражданнарга, иҗтимагый һәм бүтән төрле оешмаларга халык мәшгульлеге һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендә җәмәгатьчелек контролен гамәлгә ашыруда булышлык күрсәтә. Дәүләт функциясен үтәү буенча җәмәгатьчелек контроленең Министрлыкка тапшырылган нәтиҗәләре Россия Федерациясе законы белән билгеләнгән тәртиптә һичшиксез карап тикшерелергә тиеш.

## 7. Дәүләт функциясен үтәүче органның, шулай ук аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

7.1. Юридик затның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле, мәнфәгатьле башка затлар (алга таба – гариза бирүче) Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының тикшерү үткәргәндәге, билгеләп куелган квота чикләрендә эшкә урнаштырганда инвалидларның хокуклары бозылуга китергән карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр (судтан тыш) Россия Федерациясе законы белән билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерергә хокуклы.

Гариза бирүче язмача кәгазьдә яки электрон рәвештә шикаять белән мөрәҗәгать итәргә, шикаятен, тиңдәшле рәвештә, почта аша яки Министрлыкның “Интернет” челтәрендәге сайтыннан (http://mtsz.tatarstan.ru) файдаланып җибәрергә, шулай ук шикаятен Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә бирергә хокуклы.

7.2. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү предметы булып Министрлыкның вазыйфаи затларының дәүләт функциясен үтәгәндәге карарлары яки гамәлләре (гамәл кылмаулары) тора.

7.3. Шикаятьне карап тикшерүне туктатып тору яки аны карап тикшерүдән баш тарту өчен нигезләр күздә тотылмаган. Министрлыкның яки вәкаләтләренә тәңгәл рәвештә вазыйфаи затка кергән шикаятьнең карап тикшерелүе мәҗбүри.

7.4. Түбәндәге очракларда шикаятькә җавап бирелми яисә анда куелган сорауларга тәфсилле җавап бирелми:

- әгәр шикаятьтә шикаятьне җибәргән гариза бирүченең фамилиясе (юридик затның атамасы) яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы (электрон адрес) күрсәтелмәгән булса;

- әгәр шикаятькә сүгенү яисә мыскыллау сүзләре, вазыйфаи затның шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар кергән булса (Министрлыкның вазыйфаи заты шикаятьне җибәргән гариза бирүчегә үз хокукларыннан явызларча файдаланырга ярамау турында хәбәр итәргә хокуклы);

- әгәр язмача шикаятьнең тексты укырлык булмаса (аның фамилиясе һәм почта адресы (электрон адресы) укырлык булган очракта, шикаятьне җибәргән гариза бирүчегә, шикаять теркәлгән көннән башлап 7 көн эчендә бу хакта хәбәр

ителә);

- әгәр гариза бирүченең шикаятендә элегрәк җибәрелгән шикаятьләргә бәйле рәвештә аңа берничә тапкыр язмача тәфсилле җаваплар бирелгән сорау булса, һәм бу очракта шикаятьтә яңа дәлилләр яки шартлар китерелмәсә (министр, вазыйфаи зат яисә шуңа вәкаләтле зат чираттагы шикаятьнең нигезсезлеге турында һәм әлеге мәсьәлә буенча гариза бирүче белән язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы (әлеге шикаять һәм элегрәк җибәрелгән шикаятьләр Министрлыкка яки шул бер үк вазыйфаи затка җибәрелгән очракта); шикаятьне җибәргән гариза бирүчегә язышуны туктату турындагы әлеге карар хакында хәбәр ителә).

Әгәр шикаятьтә әзерләнүче, кылынучы яки кылынган законга каршы гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында мәгълүматлар булса, шикаять, вәкаләтенә туры китереп, дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

Суд карарына карата белдерелүче шикаять, теркәлгән көненнән башлап җиде көн эчендә, әлеге суд карарына карата шикаять белдерүнең тәртибе аңлатылып, гариза бирүчегә кире кайтарыла.

Шикаятьтә куелган сорауларга тәфсилле җавап бирү мөмкин булмауның сәбәпләре тора-бара бетерелгән очракта, гариза бирүче шикаятен Министрлыкка яки аның вазыйфаи затына кабат җибәрергә хокуклы.

7.5. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процедурасын башлау өчен нигез булып, гариза бирүчедән (гариза бирүченең вәкаләтле вәкиленнән) шәхсән, яки почта аша хат рәвешендә, яки E-mail: mtsz@tatar.ru электрон адресына җибәрелгән яки Министрлыкның рәсми сайты (http://mtsz.tatarstan.ru) аша электрон документ рәвешендә Министрлыкка мөрәҗәгать (шикаять) керү тора.

7.6. Гариза бирүчеләр шикаятьне нигезләү һәм карап тикшерү өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны алуга хокуклы. Андый төрдәге мәгълүматны һәм документларны алу өчен, гариза бирүчеләр Министрлык адресына язмача яки электрон рәвештә бу хакта рәсми мөрәҗәгать җибәрергә тиешләр.

7.7. Министрлыкның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять министрга җибәрелергә мөмкин. Министрлыкның һәм министрның гамәлләренә (гамәл кылмауларына), карарларына шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелергә мөмкин.

7.8. Шикаятьләр Министрлык тарафыннан алар теркәлгән көннән башлап 30 көн эчендә карап тикшерелә.

7.9. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүнең нәтиҗәләре булып тора:

- дәүләт күзәтчелеген һәм контролен тормышка ашыру барышында кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм кабул ителгән (башкарылучы) карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне канәгатьләндерү, ә тәгаен:

эш урынындагы тикшерү барышында вазыйфаи затның (вазыйфаи затларының) үз хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәү фактлары ачыкланган очракта, аңа (аларга) карата Россия Федерациясе законына туры китереп чаралар күрү;

Россия Федерациясе законын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшкуарга андый чаралар күрелгән көннән башлап 10 көн эчендә язмача хәбәр бирү;

- төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) тормышка ашыру барышында кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм кабул ителгән (башкарылучы) карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне канәгатьләндерми калдыру (мондый карарны дәлилле нигезләп, юридик затка, шәхси эшкуарга язмача хәбәр җибәрү юлы белән).

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тикшерүләр үткәрү, үтәлүе мәҗбүри күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән, билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелек һәм контрольлек итү дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы халык мәшгульлеге хезмәте дәүләт учреждениеләре турында мәгълүматлар

| Учреждение | Адрес | Телефон |
|---|---|---|
| “Казан шәһәре халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 420034, Казан ш., Декабристлар ур., 81 й., корп. А | (8-843) 562-48-33 |
| “Казан шәһәре халык мәшгульлеге үзәге” ДКУның Совет районындагы филиалы | 420029, Казан ш., Журналистлар ур., 13а й. | (8-843) 273-85-03 |
| “Авиатөзелеш районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 420085, Казан ш., 1 нче Муром ур., 33а й. | (8-843) 537-86-02 |
| “Вахитов районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 420059, Казан ш., Павлюхин ур., 102 й. | (8-843) 277-52-93 |
| “Киров районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 420032, Казан ш., Слободская ур., 23 й. | (8-843) 554-77-36 |
| “Мәскәү районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 420039, Казан ш., Гагарин ур., 46 й. | (8-843) 564-58-72 |
| “Яңа Савин районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 420044, Казан ш., Ибраһимов ур., 41 й. | (8-843) 560-26-95 |
| “Идел буе районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 420101, Казан ш., Бертуган Касыймовлар ур., 22/7 й. | (8-843) 224-86-66 |
| “Азнакай шәһәре халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 423330, Азнакай ш., Төзүчеләр ур., 10 й. | (8-85592) 7-57-00 |

| | | |
|---|---|---|
| “Әлмәт шәһәре халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 423450, Әлмәт ш., Герцен ур., 86а й. | (8-8553) 32-34-99 |
| “Баулы шәһәре халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 423930, Баулы ш., Энгельс ур., 56 й. | (8-85569) 5-62-29 |
| “Бөгелмә шәһәре халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 423230, Бөгелмә ш., Октябрь ур., 15 й. | (8-85594) 4-17-60 |
| “Буа шәһәре халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 422430, Буа ш., Р.Люксембург ур., 157/1 й. | (8-84374) 3-35-89 |
| “Алабуга шәһәре халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 423600, Алабуга ш., Спас ур., 5 й. | (8-85557) 7-58-58 |
| “Зәй шәһәре халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 423520, Зәй ш., Нефтьчеләр пр., 37б й. | (8-85558) 7-15-43 |
| “Зеленодольск шәһәре халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 422550, Зеленодольск ш., Татарстан ур., 1 й. | (8-84371) 5-64-90 |
| “Лениногорск шәһәре халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 423250, Лениногорск ш., Гагарин ур., 51 й. | (8-85595) 5-59-70 |
| “Чаллы шәһәре халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 423831, Чаллы ш., Сөембикә пр., 47 й. | (8-8552) 52-42-68 |
| Чаллы шәһәре халык мәшгульлеге үзәгенең Тукай районындагы филиалы | 423831, Чаллы ш., Яңа шәһәр, Сөембикә пр., 47 й. (43/20) | (8-8552) 52-42-68, 52-97-06 |
| “Түбән Кама шәһәре халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 423570, Түбән Кама ш., Бызов ур., 20а й. | (8-8555) 42-40-79 |
| “Нурлат шәһәре халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 423040, Нурлат ш., Хәмәдиев ур., 19 й. | (8-84345) 2-46-32 |
| “Чистай шәһәре халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 422980, Чистай ш., К.Маркс пр., 35 й. | (8-84342) 5-13-34 |
| “Аксубай районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 423060, Аксубай ш.т.б., Романов ур., 6 й. | (8-84344) 2-74-61 |
| “Актаныш районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 423740, Актаныш ав., Ленин пр., 61 й. | (8-85552) 3-09-83 |
| “Алексеевск районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 422900, Алексеевское э.б., Ленин ур., 87 й. | (8-84341) 2-59-00 |

| | | |
|---|---|---|
| “Әлки районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 422870, Әлки р-ны, Базарлы Матак ав., Совет ур., 8 й. | (8-84346) 2-15-21 |
| “Апас районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 422350, Апас ш.т.б., Шоссе ур., 5 й. | (8-84376) 2-12-15 |
| “Арча районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 422000, Арча ш.т.б., Банк ур., 6в й. | (8-84366) 3-29-33 |
| “Әтнә районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 422750, Олы Әтнә, Совет ур., 63 й. | (8-84369) 2-16-50 |
| “Балтач районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 422250, Балтач ш.т.б., Совет ур., 16 й. | (8-84368) 2-52-34 |
| “Югары Ослан районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 422570, Югары Ослан ав., Медгородок ур., 1 й. | (8-84379) 2-24-28 |
| “Биектау районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 422700, Биектау ав., ул. Үзәк ур., 7а й. | (8-84365) 3-16-17 |
| “Чүпрәле районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 422470, Иске Чүпрәле ав., Мәктәп ур., 16 й. | (8-84375) 2-24-51 |
| “Кайбыч районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 422330, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар ур., 7 й. | (8-84370) 2-10-06 |
| “Кукмара районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 422110, Кукмара б., Ворошилов ур., 44 й. | (8-84364) 2-67-54 |
| “Лаеш районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 422610, Лаеш ш., Первомайская ур., 16 й. | (8-84378) 2-49-31 |
| “Мамадыш районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 422190, Мамадыш ш., Муса Җәлил ур., 12 й. | (8-85563) 3-35-57 |
| “Менделеевск районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 423650, Менделеевск ш., Фомин ур., 19 й. | (8-85549) 2-02-02 |
| “Менделеевск районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУның Әгерҗе районындагы филиалы | 422230, Әгерҗе ш., Сәетов ур., 8а й. | (8-85551) 2-31-73, 2-29-84 |
| “Минзәлә районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 423700, Минзәлә ш., Ленин ур., 78 й. | (8-85555) 3-23-80 |
| “Мөслим районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 423970, Мөслим ав., Пушкин ур., 47 й. | (8-85556) 2-49-50 |

| | | |
|---|---|---|
| “Яңа Чишмә районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 423119, Яңа Чишмә ав., Ленин ур., 93 й. | (8-84348) 2-30-42 |
| “Питрәч районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 422770, Питрәч ав., Совет ур., 34 й. | (8-84367) 3-04-84 |
| “Балык Бистәсе районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 422650, Балык Бистәсе ш.т.б., Ленин ур., 48 й. | (8-84361) 2-21-81 |
| “Саба районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 422060, Байлар Сабасы ш.т.б., Тукай ур., 87 й. | (8-84362) 2-44-11 |
| “Сарман районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 423350, Сарман ав., Ленин ур., 26 й. | (8-85559) 2-42-62 |
| “Спас районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 422840, Спас р-ны, Болгар ш., Хирург Шеронов ур., 21 й. | (8-84347) 3-07-72 |
| “Тәтеш районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 422370, Тәтеш ш., Ирек мәйданы, 45 й. | (8-84373) 2-63-29 |
| “Тәтеш районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУның Кама Тамагы районындагы филиалы | 422820, Кама Тамагы ш.т.б., К.Маркс ур., 2а й. | (8-84377) 2-14-67, 2-18-84 |
| “Теләче районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 422080, Теләче ав., Ленин ур., 73 й. | (8-84360) 2-13-51 |
| “Чирмешән районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 423100, Чирмешән ав., Титов ур., 5 й. | (8-84396) 2-54-59 |
| “Ютазы районы халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | 423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин ур., 38 й. | (8-5593) 2-60-16 |

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тикшерүләр үткәрү, үтәлүе мәҗбүри күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән, билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелек һәм контрольлек итү дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына 2 нче кушымта

Юридик затларга, шәхси эшкуарларга куела торган мәҗбүри таләпләр исемлеге

| Мәҗбүри таләпләр исемлеге | Мәҗбүри таләпне билгеләүче норматив хокукый акт | Тикшерү үткәрелгәндә, юридик затлар, шәхси эшкуарлар күрсәтә торган документлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар (алга таба – эш бирүчеләр), билгеләп куелган квоталар нигезендә, алар кертелгән көннән башлап бер ай эчендә, инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын аерып бирергә, ә зарурлык булган очракта, аларны (инвалидлар өчен | № 181-ФЗ Федераль законның 24 статьясы икенче абзацының 1 пункты;<br>№ 60-ТРЗ ТР законының 3, 6 статьялары;<br>Эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә башкаручы эш бирүчеләрдә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары квотасын | Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары бүлеп бирү, ә зарурлык очрагында аларны булдыру турындагы боерыкның (әмернең) юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан расланган күчермәсе;<br>Эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә башкаручы эш бирүчеләрдә |

| | | |
|---|---|---|
| иң аз сандагы махсус эш урыннарын һәм резервта тотылучы эш урыннарын) булдырырга тиеш, шулай ук әлеге эш урыннары турында мәгълүмат кергән локаль норматив актлар кабул итәргә тиеш. | булдыру тәртибе турында № 170 ТР МК карары белән расланган нигезләмәнең 3.1 пункты | инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары квотасын булдыру тәртибе турында № 170 ТР МК карары белән расланган нигезләмәнең 3 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча халык мәшгульлеге үзәгенә мәгълүмат җибәрү турындагы хатның (хәбәрнамәнең) юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан расланган күчермәсе |
| 2. Эш бирүчеләр, инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасы нигезендә, инвалидларга эш шартлары тудырырга бурычлы. | № 181-ФЗ Федераль законның 24 статьясы икенче абзацының 2 пункты;<br>№ 60-ТРЗ ТР законының 6 статьясы;<br>Эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә башкаручы эш бирүчеләрдә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары квотасын булдыру тәртибе турында № 170 ТР МК карары белән расланган нигезләмәнең 3.1 пункты | Эш бирүченең, инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасына туры китереп, махсус эш шартларын билгели торган локаль норматив актлары күчермәләре |
| 3. Ай саен халык мәшгульлеге үзәгенә, буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфаларның, инвалидларны эшкә алу өчен билгеләп куелган квота нигезендә, | № 181-ФЗ Федераль законның 24 статьясы икенче абзацының 3 пункты;<br>№ 1032-1 Россия Федерациясе законының 25 статьясындагы 3 пункт; | Эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә башкаручы эш бирүчеләрдә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары квотасын булдыру тәртибе турында |

| | | |
|---|---|---|
| инвалидларны эшкә урнаштыру өчен булдырылган яки аерып куелган эш урыннарының булу-булмавы турында мәгълүмат тапшыру (әлеге эш урыннары хакында белешмәләр кергән локаль норматив актлар, инвалидларны эшкә алу өчен билгеләп куелган квотаның үтәлеше турындагы мәгълүматны да кертеп) | № 60-ТРЗ ТР законының 3, 6 статьялары;<br>Эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә башкаручы эш бирүчеләрдә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары квотасын булдыру тәртибе турында № 170 ТР МК карары белән расланган нигезләмәнең 3.2 пункты;<br>№ 60-ТРЗ ТР законының 6 статьясы 2 өлешендәге 2 пункт | № 170 ТР МК карары белән расланган нигезләмәнең 4 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча халык мәшгульлеге үзәгенә мәгълүмат җибәрү турындагы хатның (хәбәрнамәнең) юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан расланган күчермәсе |
| 4. Инвалидларны эшкә алу өчен квотаны үтәү (билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидны эшкә алудан нигезсез баш тартуның булмавы) | № 1032-1 Россия Федерациясе законының 25 статьясындагы 3 пункт;<br>№ 60-ТРЗ ТР законының 6 статьясы 2 өлешендәге 2 пункт | Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен билгеләп куелган квота чикләрендә бүлеп бирелгән һәм (яки) булдырылган эш урыннарына инвалидны эшкә алу турындагы боерыкның (әмернең) юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан расланган күчермәсе;<br>билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидны эшкә алудан баш тарту турындагы карарның эш бирүче тарафыннан расланган күчермәсе |
| 5. Хезмәткәр эштән азат ителгән көннән башлап ун көн эчендә эш бирүчеләрнең халык мәшгульлеге үзәкләренә бушаган, | № 60-ТРЗ ТР законының 6 статьясы 2 өлешендәге 2.1 пункт;<br>Эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы | Эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә башкаручы эш бирүчеләрдә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш |

| | | |
|---|---|---|
| билгеләп куелган квота кысасында бүлеп бирелгән яки булдырылган эш урыннары турында мәгълүмат тапшыруы | территориясендә башкаручы эш бирүчеләрдә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары квотасын булдыру тәртибе турында № 170 ТР МК карары белән расланган нигезләмәнең 3.4 пункты | урыннары квотасын булдыру тәртибе турында № 170 ТР МК карары белән расланган нигезләмәнең 5 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча халык мәшгульлеге үзәгенә мәгълүмат җибәрү турындагы хатның (хәбәрнамәнең) юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан расланган күчермәсе |
| 6. Эш бирүченең халык мәшгульлеге үзәгенә билгеләп куелган квота үтәлеше (квотаны үтәү мөмкин булмау) һәм инвалидларны эшкә алу өчен булган вакансияләр, эш бирүчеләрдә эшләүче инвалидлар саны турында мәгълүмат бирүе | № 181-ФЗ Федераль законның 24 статьясы;<br>Эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә башкаручы эш бирүчеләрдә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары квотасын булдыру тәртибе турында № 170 ТР МК карары белән расланган нигезләмәнең 3.2, 2.7, 2.14 пунктлары | Халык мәшгульлеге үзәгенә түбәндәгеләрне җибәрү турындагы хатның (хәбәрнамәнең) юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан расланган күчермәсе:<br>эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә башкаручы эш бирүчеләрдә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары квотасын булдыру тәртибе турында № 170 ТР МК карары белән расланган нигезләмәнең 4 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча инвалидны эшкә алу өчен квота үтәлеше турында мәгълүмат;<br>эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә башкаручы эш бирүчеләрдә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш |

| | | |
|---|---|---|
| | | урыннары квотасын булдыру тәртибе турында № 170 ТР МК карары белән расланган нигезләмәнең 2 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча квотаны үтәү мөмкинлеге булмау турында мәгълүмат;<br>эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә башкаручы эш бирүчеләрдә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары квотасын булдыру тәртибе турында № 170 ТР МК карары белән расланган нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча мәгълүмат |

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тикшерүләр үткәрү, үтәлүе мәҗбүри күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән, билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелек һәм контрольлек итү дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына 3 нче кушымта

Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларны ирешү өчен юридик зат, шәхси эшкуар тапшыра торган документлар исемлеге

| Тикшерү үткәрү өчен тапшырылучы документ | Документның формасын билгеләүче норматив хокукый акт |
|---|---|
| 1. Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары бүлеп бирү, ә зарурлык очрагында аларны булдыру турындагы боерыкның (әмернең) юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан расланган күчермәсе | - |
| 2. Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен билгеләп куелган квота чикләрендә бүлеп бирелгән һәм (яки) булдырылган эш урыннарына инвалидны эшкә алу турындагы боерыкның (әмернең) юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан расланган күчермәсе | - |

| | |
|---|---|
| 3. Билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидны эшкә алудан баш тарту турындагы карарның юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан расланган күчермәсе | - |
| 4. Халык мәшгульлеге үзәгенә түбәндәге мәгълүматны җибәрү турындагы хатның (хәбәрнамәнең) юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан расланган күчермәсе: | |
| - эш бирүчедә эшләүче инвалидлар саны турында; | Эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә башкаручы эш бирүчеләрдә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары квотасын булдыру тәртибе турында № 170 ТР МК карары белән расланган нигезләмәнең 1 нче кушымтасы; |
| - квотаны үтәү мөмкин булмауның объектив шартлары (сәбәпләре) турында; | Эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә башкаручы эш бирүчеләрдә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары квотасын булдыру тәртибе турында № 170 ТР МК карары белән расланган нигезләмәнең 2 нче кушымтасы; |
| - инвалидларны эшкә урнаштыру өчен билгеләп куелган квота чикләрендә эш урыннары бүлеп бирү һәм (яки) аларны булдыру турында; | Эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә башкаручы эш бирүчеләрдә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары квотасын булдыру тәртибе турында № 170 ТР МК карары белән расланган нигезләмәнең 3 нче кушымтасы; |
| - бушаучы эш урыннары, билгеләп куелган квоталар кысасында бүлеп бирелгән яки | Эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә башкаручы эш |

| | |
|---|---|
| булдырылган эш урыннары турында | бирүчеләрдә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары квотасын булдыру тәртибе турында № 170 ТР МК карары белән расланган нигезләмәнең 5 нче кушымтасы |
| 5. Халык мәшгульлеге үзәгенә инвалидларны эшкә алу өчен билгеләп куелган квота үтәлеше һәм булган вакансияләр турында мәгълүмат җибәрү хакындагы хатның (хәбәрнамәнең) юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан расланган күчермәсе | Эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә башкаручы эш бирүчеләрдә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары квотасын булдыру тәртибе турында № 170 ТР МК карары белән расланган нигезләмәнең 4 нче кушымтасы |

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тикшерүләр үткәрү, үтәлүе мәҗбүри күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән, билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелек һәм контрольлек итү дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына 4 нче кушымта

**Тикшерүләр үткәрү, үтәлүе мәҗбүри күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән, билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелек һәм контрольлек итү дәүләт функциясен үтәүнең блок-схемасы**

Билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуны план буенча урынга барып һәм план буенча документларны тикшерүләр үткәрү

Билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуны планнан тыш урынга барып һәм планнан тыш документларны тикшерүләр үткәрү

Урынга барып һәм документларны тикшерүләр үткәрү планын әзерләү һәм раслау

Инвалидлар өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендә закон бозулар турында мәгълүмат керү

План буенча урынга барып тикшерү үткәрү турындагы боерыкны (әмерне) раслау

План буенча документларны тикшерү үткәрү турындагы боерыкны (әмерне) раслау

Планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрү турындагы боерыкны (әмерне) раслау

Планнан тыш документларны тикшерү үткәрү турындагы боерыкны (әмерне) раслау

План буенча урынга барып тикшерү үткәрү турында оешмага хәбәр итү

План буенча документларны тикшерү үткәрү турында оешмага хәбәр итү

Планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрү турында оешмага хәбәр итү

Планнан тыш документларны тикшерү үткәрү турында оешмага хәбәр итү

Оешманың план буенча документларны тикшерү үткәрү өчен кирәкле материаллар һәм документларны бирүен сорап, рәсми мөрәҗәгать (таләп) җибәрү

Оешманың планнан тыш документларны тикшерү үткәрү өчен кирәкле материаллар һәм документларны бирүен сорап, рәсми мөрәҗәгать (таләп) җибәрү

1

1

↓

Тикшерү үткәрү

↓

Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле хезмәткәрләр оешманың бу Административ регламентның 2 нче кушымтасында бәян ителгән мәҗбүри таләпләрне үтәвен тикшерә, шул исәптән:
оешманың билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннары бүлеп бирү (булдыру) турында халык мәшгульлеге үзәгенә мәгълүмат бирүен (инвалидларны эшкә алу өчен оешма бүлеп биргән (булдырган) эш урыннары (шул исәптән махсус урыннар) санының инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендә закон таләпләренә туры килүен);
оешманың инвалидларны эшкә урнаштыру өчен билгеләнгән квота үтәвен (билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидны эшкә алудан нигезсез баш тартуның булмавын);
оешманың бушаучы эш урыннары, билгеләп куелган квота чикләрендә бүлеп бирелгән яки булдырылганнары турында халык мәшгульлеге үзәгенә мәгълүмат бирүен;
оешманың инвалидларны эшкә алу өчен квотаның үтәлеше турында халык мәшгульлеге үзәгенә мәгълүмат бирүен

↓

Тикшерү актын төзү

↓ ↓

| | |
|---|---|
| Закон бозулар ачыкланды | Закон бозулар ачыкланмады |

\/

Инвалидлар өчен эш урыннары квотасын булдыру өлкәсендә закон бозылу булганда, шулай ук административ хокук бозу составы билгеләре булу-булмауга бәйле рәвештә, Министрлыкның юридик бүлегенең вазыйфаи

булу-булмауга бәйле рәвештә, Министрлыкның юридик бүлегенең вазыйфаи

заты:

Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының 5.42 статьясындагы 1 өлеше белән күздә тотылган административ хокук бозу турында беркетмә төзи;

Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының кодексының 19.7 статьясы белән күздә тотылган административ хокук бозу турында беркетмә төзи.

Җаваплы башкаручы, ачыкланган закон бозуларны бетерүнең срогын күрсәтеп, амәлдәге законны бозуларны бетерү турында үтәлүе мәҗбүри булган күрсәтмә бирә

|
\/

Гамәлдәге законны бозуларны бетерү турындагы күрсәтмә белән билгеләнгән срокта Министрлыкка аларның бетерелүе турында мәгълүмат кермәгән очракта, җаваплы башкаручы гаепле затларны Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының 19.5 статьясының 1 өлеше нигезендә административ җаваплылыкка тарту өчен нигезләр булуын раслаучы документлар һәм материалларны кушып, хезмәт итү запискасын әзерли һәм Министрлыкның юридик бүлегенә җибәрә.

Министрлыкның юридик бүлегенең вазыйфаи заты Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының 19.5 статьясындагы 1 өлеше белән күздә тотылган административ хокук бозу турында эш кузгата.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тикшерүләр үткәрү, үтәлүе мәҗбүри күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән, билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелек һәм контрольлек итү дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына 5 нче кушымта

(Үрнәк форма)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгы хаты бланкында

**Ачыкланган закон бозуларны бетерү турында**
**КҮРСӘТМӘ № __**

“__”________ 20__ ел

________________________________________
(күрсәтмәне бирү урыны: торак пункт атамасы)

________________________________________________________________________
(эш бирүченең вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме, тулы атамасы)

“__” ________ ел. дан “__” ________ ел. га кадәрге чорда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының вазыйфаи затлары тарафыннан тикшерү үткәрелде ________________________________________________
________________________________________________________________________
(эш бирүчеләрнең билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә кабул итү турындагы законны үтәвен, билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә урнаштыру өлкәсендә закон бозуларны ачыклау)

________________________________________________________________________
(эш бирүченең тулы атамасы)
________________________________________________________________________

“Россия Федерациясендә халык мәшгульлеге турында” 19.04.1991 ел, № 1032-1 законына туры китереп һәм “__” ________ 20__ ел, № __ тикшерү акты нигезендә, ачыкланган бозуларны бетерергә һәм түбәндәге таләпләрне үтәүне мәҗбүри итеп куям:

| Т-п № | Закон бозуларны бетерү турында тикшерү актында күрсәтелгән таләпләр исемлеге |
|---|---|
| | |
| | |
| | |

_______________________________ (күрсәтмә чыгарган затның вазыйфа атамасы)

_______________________________ (Ф.И.О.)

_______________ (имза)

Үтәү өчен күрсәтмәне алдым:

______________________ (вазыйфа)

_______________________________ (Ф.И.О.)

_______________ (имза)